... КИТАП SAQLAV BYLESE
ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ
им. ЛЕНИНА БИБЛИОТЕКИ АТССР г. Казань
Уг. Кw 27

ДҮШӘМБЕ
4 МАРТ
1940 ел
№ 52 (5852)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Навигациягә большевистик хәзерлекне тәэмин итик

Халык хуҗалыгының кызу темп белән үсүе су юлы транспортының үрнәкле эшләвен, дәүләт тарафыннан бирелгән заданиеләрне тәгәл үтәвен таләп итә. Безнең илебездә йөк әйләнеше һәр ел саен зуррак күләмнәр ала бара. Су юлы транспортының халык хуҗалыгына хезмәт күрсәтүен яхшырту, бигрәк тә массовый йөкләр: агач, ашлык, күмер һәм нефть ташуда аның ролен арттыру иң әһәмиятле бурычларның берсе.

1940 нчы елның навигациясе башлануга санаулы көннәр генә калып бара. Бу җаваплы һәм мактаулы эшкә алдан ныклы хәзерлекне тәэмин итәргә, судноларга, йөк төяү һәм бушату механизмнарына, складларга, дебаркадерларга ремонт ясауны тәгәл һәм югары сыйфатлы итеп үтәргә, пристаньнәрне үрнәкле һәм культуралы тәртипкә китерергә кирәк. Болар барсы да навигациянең уңышлы башлануы, беренче көннәрдә үк йөк ташу планының үтәлүе өчен практик шартлар тудыру дигән сүз.

Йөк әйләнеше планын үтәү—транспортның һәрбер работнигы өчен ныклы закон. Аны тулы үтәү өчен, барыннан да элек судноларга ремонт ясауны дәүләт тарафыннан билгеләнгән срокларда югары сыйфатлы итеп үтәргә кирәк.

Республикабызда судноларга ремонт ясауның югары үрнәкләрен бирүче производство командирлары, инженер-техник работниклар, стахановчы токарьлар, механиклар, судно командалары аз түгел. Алар хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча өченче бишьеллык планны дүрт елда үтәү өчен Москва инструментальчыларының чакыруларына эш белән җавап бирәләр. Моңа Чистайда судноларга ремонт ясау заводы ачык мисаль булып тора.

Бу завод элек еллар буенча артта калып килә иде. Завод җитәкчеләре үткәндәге җитешсезлекләрне кабатламау өчен бөтен чараларны күрделәр. Иң әһәмиятлесе шунда, алар производство мәсьәләләре белән якыннан торып шөгыльләнәләр, үтәлешне системалы рәвештә тикшереп баралар. Биредә бөтен коллектив дәүләт заданиеләрен үтәүгә тупланган. Коллектив Дзержинский исемендәге завод белән ярыша. Социалистик ярыш бик яхшы нәтиҗәләр бирә. Чистай заводы коллективы судноларга ремонт ясау планын һәр ай саен арттырып үти. „Балхаш", „Камская 15", „Жемчужина" һәм башка пароходларга ремонт ясау планы срогыннан алда төгәлләнде. Стахановчылар хезмәт җитештерүчәнлегенең сокланырлык үрнәкләрен бирәләр. Район советы депутаты, токарь иптәш Гибалин бер үзе биш станокта эшли. Ул норманы 1.450 процент үтәп, эшендәге бай тәҗрибәсен башкалар белән уртаклашып килә. Мастер Гагарин җитәкчелек итә торган электросварка цехы стахановчылары Салахов, Поспелов, Милютин һәм башка иптәшләр норманы 400—500 процент итеп үтиләр. Алар аз түгел һәм алар заводның үрнәкле эшләве өчен зур тырышлык күрсәтәләр.

Навигациягә хәзерлектә зур гына уңышлар булу белән бергә, бу өлкәдә кимчелекләр дә юк түгел. Халык хуҗалыгының бу тармагында эшләүче работникларның кайберләре үз бурычларын үтәүдән ерак торалар әле. Алар производствога большевистик һәм оператив җитәкчелекне тәэмин итәсе, нормаль эш шартлары тудырасы урынга, озын-озын карарлар, приказлар чыгару белән генә чикләнеп калалар. Үтәлешне тикшермиләр, алдынгы кешеләрнең инициативаларын күреп җиткермиләр, хуҗасызлыкка, иясезлеккә каршы тиешенчә көрәшмиләр.

Аракчино затоны судноларга ремонт ясау планын шушы елның бер генә аенда да үтәгәне юк. План үтәлмәүнең сәбәбе нәрсәдә соң? Моның сәбәбе затон җитәкчеләренең үзләрендә. Алар производство мәсьәләләре белән бик аз шөгыльләнәләр, кадрлар „җитешмәүдән" зарланалар. Квалификацияле кадрлар җитештерү буенча затон җитәкчеләре үзләрендә булган мөмкинлекләрне күрергә теләмиләр. Мәсәлән, затонда йөзләрчә хатын-кызлар эшли. Алар арасында төрле профессияләрне үзләштерергә, күп станокларда эшләргә теләүчеләр бик күп. Шулай булуга карамастан, хатын-кызларның күпчелеге ярдәмче эшләрдә генә файдаланыла. Яисә башка бер факт. Инициативалы эшче иптәш Медведев ремонт башланганнан бирле күп станокта эшли. Стахановчылык хәрәкәтендәге бу яңалыкны башлап җибәрүчеләрнең берсе итеп затонда иптәш Медведевне күрсәтергә мөмкин. Шулай да, затон җитәкчеләре күп станокчыларның тәҗрибәләрен өйрәнү, бу гүзәл хәрәкәтне үстерү буенча бер төрле дә практик чара күрмиләр.

Йөк ташу буенча төрле оешмалар белән алдан ук договорлар төзү 1940 нчы ел навигациясенә хәзерлекнең әһәмиятле чараларыннан берсе булып тора. Кайбер пристаньнәр бу тармакта акырын кузгалалар әле.

Кама Тамагы пристанен алып карыйк. Бу пристань ике елганың тоташкан урнындагы гаять әһәмиятле узел. Аның аркылы меңнәрчә тонна йөкләр үтә. Пристань җитәкчеләре сәүдә һәм башка оешмалар белән договорлар төзүгә гадәттән тыш салкын карыйлар.

Безнең илебездә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча өченче бишьеллыкны дүрт елда үтәү өчен миллионнар социалистик ярыш байрагын югары күтәрәләр. Москвадагы инструменталь заводы коллективының чакыруы халык хуҗалыгының бөтен тармакларында эшләүчеләрне дәртләндерде, хезмәт җитештерүчәнлегенең яңа күтәрелешенә туплады.

Тимер юл транспортында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча папавинчылар хәрәкәте киң җәелә. Паровоз эшенең техникасын отлично үзләштереп, иптәш Папавин паровозны тиз йөртү буенча әлегәчә күрелмәгән үрнәк бирде. Су юлы транспорты работниклары тимер юлдагы бу яңалыкны үзләштерергә, папавинчылар хәрәкәтенә кушылырга тиешләр.

1940 нчы елның навигациясенә үрнәкле хәзерлек—су юлы транспортында эшләүче барлык работникларның, урыннардагы җәмагат оешмаларының мактаулы бурычлары.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

2 нче мартта Карелия бугазында безнең частьләрнең һөҗүме уңышлы рәвештә киңәюдә дәвам итте. Безнең частьләр **Выборг** тимер юлы станциясе депосын һәм **Выборг** шәһәренең төньяк өлешен алдылар һәм **Выборгдан** төньякта **Таммисуо** станциясен һәм **Выборгдан** төньяк-көнбатышта **Кейхясниеми** мысын һәм **Туркинсаари** атавын алдылар. Болардан тыш **Выборгдан** көнчыгышта безнең частьләр **Кяянтима** һәм **Лапинлахти** местечколарын алдылар.

Фронтның башка участкыларында әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация дошманның гаскәрләренә һәм аның сугыш объектларына актив хәрәкәтләр алып барды. Һавада булган сугышларда дошманның 7 самолеты бәреп төшерелде.

ВКП(б) ның Татарстан өлкә оешмасының XXI нче конференциясе делегатлары игтибарына

Партиянең Татарстан өлкә оешмасының XXI нче конференциясе шушы елның 10 нчы мартында, 18 сәгаттә, Менжинский исемендәге клубта ачыла. (Казан, Карл Маркс урамы, 26).

Делегатларны теркәү һәм делегатлык билетлары бирү 8 һәм 9 нчы мартта 9 сәгаттән 23 сәгаткә кадәр һәм 10 нчы мартта 9 сәгаттән 16 сәгаткә кадәр, ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты бинасында, 35 нче бүлмәдә булачак (Казан, Б. Красный урам, 38). Оештыру комиссиясенең телефоннары: 26—80, 13—30, яки Өлкә Комитеты коммутаторы аркылы—10.

Оештыру комиссиясе.

Партиянең Казан шәһәр оешмасының V нче конференциясендә.

И. Галиев фотосы.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

МТС ларга ягулык китертүдәге өзеклекне бетерергә

МТС лар язгы кыр эшләре өчен ягулык һәм майлау материалларын чана юлы өзелгәнче ташып куярга тиешләр. Ләкин бу эшнең барышы һич тә канәгатьләнерлек түгел. Майлау материаллары ташу турында исә учет та юк.

Чиябаш МТС ында (директоры иптәш Галимов) 70 тонна урнына бары 2 тонна, Каргалы МТС ында (директоры иптәш Хәсәнев) 45 тонна урнына бары 8 тонна, Биектау МТС ында 86 тонна урнына бары 22 тонна гына ягулык кайтарылган. Минзәлә, Биләр, Ромадан, Морт МТС ларында да ягулык ташуның барышы гафу ителмәслек дәрәҗәдә начар тора.

Газогенераторлы тракторларга ягулык хәзерләү эше тагын да начар. Бу тип тракторларга быелгы сезон өчен кирәкле 130 мең кубометр урнына бары 66 мең кубометр утын хәзерләнгән. Шуның да бары 5.000 кубометры гына шакмакка туралган. Әлки МТС ында (директоры иптәш Бикулов) 2.800 кубометр урнына 1.975 кубометр, Биләр МТС ында (директоры иптәш Кадыйров) 3.100 кубометр урнына 1.445 кубометр гына хәзерләнгән.

Ягулык һәм майлау материаллары белән тәэмин итүдә МТС-ларга булышлык итәргә тиешле күп кенә оешмалар аерым хәлләрдә үзләре тоткарлык ясыйлар. Балтач МТС ы Шәмәрдән леспромхозыннан 1.400 кубометр, Мәлки МТС ы Кайбыч леспромхозыннан 400 кубометр утын алырга тиеш булганнар. Бу МТС лар тиешле акчаны түләп, утын алырга баргач, леспромхозларда хәзерләнгән утын булмаган. Хәзер бу МТС лар бөтенләй утынсыз калганнар.

Татнаркомзем белән Главнефтьнең килешеп эшләмәүләре аркасында ягулыкларны МТС ларга бүлү һәм МТС ларны нефть базаларга беркетүдә күп кенә аңлашылмаулар килеп чыга һәм эштә тоткарлыклар туа. Мәсәлән, Зур Тархан МТС ы Тәтеш нефте-базасына 30 километр чамасы ераклыкта. Ә Зур Тархан МТС ы үзеннән 85 километр ераклыктагы Кама Тамагы нефте базасына беркетелгән.

Сельхозснаб яңа оештырылган МТС лар өчен быел 200 данә агач мичкә һәм бензин салу өчен 2.000 данә бедон хәзерләргә тиеш булган. Фактта ул аларның берсен дә хәзерләмәгән. Гомумән, ягулык һәм майлау материаллары өчен таралар хәзерләү, булганнарына ремонт ясауда җавапсызлык хөкем сөрә. Заинский МТС ында 60 мичкәгә, Беренче Май МТС ында 81 мичкәгә, Мөслим МТС ында (Чистай районы) 15 мичкәгә ремонт ясарга кирәк.

МТС ларны ягулык - майлау материаллары белән тәэмин итүдәге җитешсезлекләрне бетерүдә кискен чаралар күрергә, ягулыкларны чана юлы белән ташып куюга ирешергә кирәк. *А. В.*

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ЯХШЫ ХӘЗЕРЛӘНӘЛӘР

Кызыл Йолдыз районының Таулар авылы, „Ирек" колхозы язгы чәчүгә яхшы хәзерләнә. Колхоз кырга 2.400 йөк урнына 2.718 йөк тирес чыгарды. Чәчүлек орлык җитәрлек күләмдә хәзерләнде. Орлыклык участкыга чәчү өчен 102 центнер бодай иң яхшы сыйфатлы итеп хәзерләнеп, 8 центнеры кул белән чүпләнде. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт төгәлләнде.

„Ирек" колхозы йөзпотчылар хәрәкәтенә кушылып, „Ярославель" колхозын ярышка чакырды. Бригадалар арасында да социалистик ярыш киң җәелдерелде. Колхозның 44 эш аты бар. Язгы чәчү вактында ашату өчен атларга 187 центнер концентрат азык һәм печән хәзерләнеп куелды.

Сәйфеттинев.

МТМ ДОГОВОРНЫ ҮТӘМИ

Мөслим районының Алга МТС ында тракторларга ремонт эшенең барышына Бөгелмә МТМ ы зур тоткарлык ясый. МТМ договор буенча 1939 нчы елның дүртенче кварталында 14 моторга һәм бу елның январь, февраль айларында 14 моторга ремонт ясарга тиеш иде. Ул әле бары 13 трактор моторына гына ремонт ясап бирде.

Трактор моторларына ясалган ремонтның сыйфаты начар. Подшипниклар начар эшләнгән, шатун болтлары дөрес утыртылмаган h. б.

Моторларны ремонтлаган өчен МТС ларның МТМ нарга акча түләү тәртибе турында Дәүләт банкысының Татарстан конторасыннан рәсми күрсәтмә бар. Бу күрсәтмә буенча, моторларны ремонтлау өчен акча түләү банкның район бүлекчәсе аркылы эшләнә. Шушы күрсәтмәгә таянып банкның Мөслим бүлекчәсе МТМ нан эшне кабул итеп алу турында акт-счет тапшыруны сорый һәм шуны тапшырганнан соң гына МТМ га акча күчерә. Бөгелмә МТМ-ы җитәкчеләре бу тәртипне белсәләр дә, эшкә бюрократларча карыйлар. Алар ремонтланган моторлар өчен алдан акча түләүне сорыйлар. Алдан акча түләмәгән өчен МТМ безнең ремонтланган моторларны бирмичә, 134 километрдан барган 18 атны кире борып җибәрде.

Татнаркомзем МТМ нарның эшенә акча түләү тәртибе турында Дәүләт банкысы белән килешеп МТС ларга һәм МТМ нарга ачык күрсәтмә бирергә тиеш иде. Ләкин Татнаркомземның моны эшләгәне юк. Шуның аркасында эштә күп кенә тоткарлыклар туа һәм МТС лар белән МТМ нар арасында аңлашылмаулар килеп чыга.

Бәдреттинов.
Алга МТС ы директоры.

„ДИНАМО" КОЛХОЗЫНДА ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК ЙОМШАК

Арча районының „Динамо" колхозы язгы чәчүгә начар хәзерләнә. Бу колхозда ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы карары һәм авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе мөрәҗәгате колхозчылар арасында өйрәнелмәгән, алдынгыларның эш тәҗрибәләре башкаларга күчерелми.

Бригадалар һәм колхозчылар арасында социалистик ярыш оештырылмаган. Чәчүлек орлыклары 700 центнер урнына бары 280 центнер гына хәзерләнгән. Язгы чәчү вактына атлар өчен фураж бүленеп куелмаган. Икенче һәм өченче бригадаларда атларны карау эше балаларга тапшырылган.

Колхозда 52 баш атка бары 25 камыт бар. Арбаларның берсе дә төзек түгел. План буенча 43 центнер фекали, 50 центнер кош тизәге һәм 23 тонна минерал ашлама хәзерләнергә тиеш иде, ләкин алар хәзерләнмәгән әле. 1.500 йөк урнына бары 508 йөк тирес чыгарылган. Агротехниканы өйрәнү түгәрәкләрендә бары ике тапкыр занятие үткәрелгән. Колхозда производство планы һаман да төзелмәгән. Колхозчылар язгы чәчү вактындагы эш нормаларын белмиләр. Колхозда хезмәт дисциплинасы начар. Колхоз председателе Әхмәдуллин һәм хисапчы Сафиуллин эчүчелеккә бирелгәннәр.

Шакуров.

ТОРФ—ИГЕН УҢЫШЫН АРТТЫРА

Чаллы районының „Восходящая Заря" колхозы торфны ашлама сыйфатында файдалану буенча берничә елдан бирле инде тәҗрибә үткәреп килә.

1937 нче елда колхозның беренче бригадасында тәҗрибәче иптәш Палечкин инициативасы буенча бер участкы торф белән ашланып, анда бәрәңге утыртылган иде. Бу участкыда гектардан 34 центнер өстәмә уңыш алынды. Шул ук елны бер урында бәрәңге участкысы тирес һәм торф белән ашланган иде. Анда ашланмаган участкыларга караганда 38 центнер уңыш артыграк чыкты.

1938 нче елда колхозның 7 нче бригадасы уҗым участкысын торф белән ашлаган иде. Бу участкының гектарыннан 13 центнер, ә торф белән ашланмаган участкыларның гектарыннан бары 10 ар центнер уңыш алынды.

„Восходящая Заря" колхозы торфны ашлама сыйфатында быел тагын да киңрәк күләмдә куллануны планлаштыра.

(ТатТАСС).

ВКП(б) ның Казан шәһәр конференциясе ачылды

Кичә кич сәгать 6 да, Менжинский исемендәге клубның зур залы ВКП(б) ның Казан шәһәр конференциясе делегатлары һәм шәһәрнең партия, совет һәм җәмагат оешмаларыннан чакырылган кунаклар белән шыгырым тулган иде. ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм Шәһәр Комитеты секретаре иптәш А. М. Алемасов ВКП(б) ның Казан шәһәр оешмасының IV нче конференциясе белән V нче конференциясе арасындагы чорның партиябез һәм бөтен илебез тормышында тарихи әһәмияткә ия булган вакыйгаләргә бай икәнлеген күрсәтеп үтте.

— Партиябезнең бу чор эчендә үткән тарихи XVIII съезды илебезнең гигант адымнар белән үсү программасын биреп, социализмнан коммунизмга теземле рәвештә күчү полосасын билгеләү съезды булды.

Совет халкы Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия хезмәт ияләрен Польша паннары изүеннән коткарды һәм хәзер Финляндия хезмәт ияләренә азатлык яулап алу өчен героик көрәш алып бара.

Большевиклар партиясе җитәкчелегендәге совет халкы бу чор эчендә социалистик хуҗалыкның барлык тармакларында гаять зур яңа уңышларга иреште. Бу уңышлар өчен ул, барыннан да элек, бөек партиябезгә һәм юлбашчыбыз иптәш Сталинга бурычлы.

Отчет-сайлау кампаниясе партиябез тормышында иң бөек вакыйгаләрнең берсе булып тора. Казан шәһәр большевикларының V нче конференциясе партиябезнең XVIII съезды карарларының үтәлешен тикшерер, тәнкыйть һәм үзеңне тәнкыйтьләүне киң җәелдерү нигезендә партиянең Казан шәһәр оешмасы эшендә булган барлык җитешсезлекләрне ачып салыр һәм алдагы эш өчен, тагын да зур җиңүләргә ирешү өчен конкрет юллар билгеләр.

Партиянең башлангыч һәм район оешмаларында булып үткән отчет-сайлаулар безнең партиябезнең корычтай нык икәнлеген һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты тирәсенә, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин тирәсенә нык тупланганлыгын тагын бер тапкыр күрсәтте.

Яшәсен ВКП(б)! Яшәсен бөек Сталин! (Конференциягә катнашучылар бар да аяк үрә баскан хәлдә, иптәш Сталин хөрмәтенә озакка сузылган көчле алкышлар ясыйлар).

Аннары, иптәш Алемасов ВКП(б) ның Казан шәһәр конференциясен ачык дип иглан итә.

Конференциянең президиумына бер тавыштан: Абдульманов, Алемасов, Ананьев, Арнаутов, Барышников, Бычков, Гафиятуллин, Гаязеттинов, Гринько, Динмөхәметов, Долотказин, Измайлова (опера театры партоешмасыннан) Измайлова, Киселев, Матвеев, Михайлин, Михайлов, Морозов, Мөхәметов, Нацибуллин, Перов, Рундаев, Рябинин, Тихонов, Шмельков иптәшләр сайланалар.

Конференциянең почетлы президиумын сайлау турындагы тәкъдим бик зур күтәренкелек һәм алкышланып каршы алына. Көчле кул чабулар астында почетлы президиумга: **Сталин, Молотов, Ворошилов, Каганович, Калинин, Микоян, Андреев, Жданов, Хрущев, Берия, Шверник, Маленков, Димитров** һәм **Тельман** иптәшләр сайланалар.

Конференциянең секретариаты: Абдрахманов, Анушкин, Лебедев, Нежданов, Прокофьев, Скворцов һәм Федоров иптәшләр составында; мандат комиссиясе: Забродченко, Иванов, Мельников, Филиппов, Хәмидуллин, Софонов һәм Захаров иптәшләр составында сайлана.

Көн тәртибе һәм регламент расланганнан соң, конференция ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитетының эше турында иптәш А. М. Алемасовның отчет-докладын тыңлауга күчә. Делегатлар иптәш Алемасовның бай эчтәлекле докладын зур игтибар белән тыңладылар.

Аннан соң, ВКП(б) Шәһәр Комитетының ревизия комиссиясенең эше турында иптәш Ситников отчет-доклады ясады.

Конференциянең беренче утырышы шуның белән тәмам булды.

Партиянең район конференцияләре һәм жыелышлары

Мөһим мәсьәләләргә җидди караш булмаган

(Махсус хәбәрчебездән телефон буенча)

Кичә, партиянең Кызыл Йолдыз район җыелышы тәмам булды. Райком секретареның отчет-доклады буенча 31 кеше чыгып сөйләде. Алар уңышлы якларны күрсәтү белән бергә, райкомның җидди кимчелекләренә тукталдылар. Райком авыл хуҗалыгына тиешенчә җитәкчелек итмәгән. Бөртекле культуралар буенча 1939 нчы елгы уңыш 1938 нче елгы уңыштан 12 процент түбән булган. Ләкин моңардан райком җитәкчеләре үзләре өчен тиешле нәтиҗә ясамаганнар. Бу районда язгы чәчүгә хәзерлек эше начар тора. Мәсәлән, чәчү орлыкларының бары тик 51 проценты гына чистартылган. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт планының яртысы гына үтәлгән. Кырга тирес чыгару планы 36, торф һәм башка ашлама хәзерләү планы 25 процент кына үтәлгән. Ат сбруйлары һәм транспорт коралларының нинди хәлдә икәнен белү мөмкин түгел. Чөнки аларның өчтән бер өлеше аерым колхозчылар кулында саклана. Район җир бүлеге аппараты кадрлар белән тиешенчә ныгытылмаган. Бигрәк тә МТС начар эшли. Тракторларга ремонт планы 46 процент кына үтәлгән. Паркка яңадан 34 тракторчы җитми.

Филиппов, Шәрипова, Якупов, Исмагыйлев иптәшләр җыелыш игтибарын кадрларга коммунистик тәрбия бирү мәсьәләләренә юнәлдерделәр.

Җыелыш 23 кешедән пленум составы сайланды. Аларның яртысы райком составына беренче тапкыр сайланучылар.

Пленумның 2 нче мартта булган беренче утырышында райком секретарьлары һәм 7 кешедән бюро сайланды, бүлек мөдирләре расланды. Беренче секретарь итеп Юсупов, икенче секретарь итеп Юнусов, кадрлар буенча секретарь итеп Имаметтинов иптәшләр сайландылар.

Н. Мәҗитев.

ТӘТЕШ КОММУНИСТЛАРЫНЫҢ РАЙОН КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

(Телефон буенча)

29 нчы февральдә, Тәтеш районы большевикларының конференциясендә ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Плечков отчет-доклады белән чыкты. 1—2 нче мартта доклад буенча фикер алышулар булды. Барсы 30 кеше чыгып сөйләде. Алар райкомның эшендәге уңышларны күрсәтү белән бергә, җитешсезлекләрне дә ачып салдылар һәм тәнкыйтьләделәр.

Отчет чорында районның алдынгы кешеләреннән 198 кеше партия сафына кабул ителгән. 97 кеше партия, совет һәм авыл хуҗалыгы буенча җитәкче эшләргә күтәрелгән.

Район активистларыннан 32 кеше, „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнүне тәгәлләп, хәзер партия тарихын төп чыганаклар буенча өйрәнә. 65 кеше „кыскача курс“ ның VIII—IX нчы бүлекләрен өйрәнү өстендә эшли.

Ләкин партия пропагандасы буенча җидди кимчелекләр бар әле. Мәсәлән, коммунистлардан 75 кеше ВКП(б) тарихын өйрәнү эшенә бөтенләй керешмәгән. Алар арасында районның җитәкче работниклары да бар. Мәсәлән, район прокуроры Бронников, район җир бүлеге мөдире Сухарев, Заготзерно управляющие Зуев иптәшләрне күрсәтергә була.

Райондагы күпчелек колхозларда хезмәт дисциплинасы әле һич тә канәгатьләнерлек түгел. 1939 нчы елда районда 329 кеше бер генә хезмәт көне дә эшләмәгән. Ә 1.400 кеше дәүләт тарафыннан билгеләнгән хезмәт көне минимумын үтәмәгән. Бу фактлар колхозларга җитәкчелек йомшак булуын күрсәтәләр.

Г. Шарапов.

Чистайда судноларга ремонт ясау заводы парткабинетында. РӘСЕМДӘ: Кама пароходчылыгы политотделы пропагандисты Г. Т. Бирюлев „ВКП(б) тарихының кыскача курс“ы буенча лекция үткәрергә хәзерләнә.

А. Колчин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

УРЫНЛЫ ТӘНКЫЙТЬ

(Махсус хәбәрчебездән телефон буенча)

ВКП(б) ның Әгерҗе район конференциясендә райком секретаре иптәш Миңнегалиевнең отчет-доклады буенча фикер алышуларда катнашучы делегатлар барсы да диярлек райком эше турында сөйләгәндә партия-пропагандасының торышы, кадрлар белән эшләү, политик-тәрбия эшләрендә райкомның җитәкчелегенә тукталдылар һәм бу очраклы түгел. Чөнки һәрбер эшне уңышлы үтәү, барыннан да элек, кадрларга бәйләнгән.

Билгеле, райкомның бу өлкәдә кайбер уңышлары бар. Отчет чорында районның иң алдынгы кешеләреннән партия сафларына 343 кеше кабул ителгән. Аларның 56 сы хатын-кызлар. Җитәкче эшләргә 66 кеше күтәрелгән һәм башкалар.

Ләкин болар башлангыч уңышлар гына. Райком пропаганда эше, кадрлар белән—актив белән эшләү турында аз кайгырткан.

Районда төрле җитәкче эшләрдә эшләүчеләрдән 42 кеше белән күптән түгел үткәрелгән беседа вактында „кыскача курс“ны өйрәнүне 2 генә кешенең тәгәлләве, 5 кешенең V—VI—VII бүлекләрне укулары, 33 кешенең I—IV нче бүлекләрдә генә утырулары билгеле булган.

Делегатлар кайбер работникларның, әнә шулай үз эсләрендә эшләмәүләре нәтиҗәсендә, массаның өзлексез үсеп бара торган политик таләпләренә җавап бирә алмауларын күрсәтә торган конкрет фактлар китерделәр.

Райкомның төп җитешсезлекләреннән берсе шунда, ул һәрбер работникка индивидуаль якын килүне, аны өйрәнүне кулланмаган, үзләренең теоретик арталыкларын бетерүгә теләмәүчеләргә карата җәмагать фикерен туплау белән аз шөгыльләнгән.

Район җир бүлеге, МТС һәм партиянең күп кенә башлангыч оешмалары югары иген уңышы алу өчен көрәшне тиешенчә оештырмаганнар. Ә райком бу оешмалардан тиешенчә эш таләп итмәгән. Колхозчылар арасында масса-аңлату эшләре йомшак. Үткән ел районда 1.571 кешенең билгеләнгән хезмәт көне минимумын тутырмавы, 212 кешенең бер генә дә хезмәт көне эшләмәүләре моны ачык күрсәтә. МТС тракторлар белән эшләү планын ел саен өзеп килә. Үткән ел план 81,7 процентка гына үтәлгән. Районда тунга сөрү планы 56 процентка гына үтәлгән. Дәүләт алдындагы йөкләмәләр әле үтәлеп бетмәгән. Район җитәкчеләре бу җитешсезлекләрне кабатламау өчен быел барлык чараларны күрергә тиешләр иде. Ләкин алар аны эшләмәгәннәр. Язгы чәчүгә хәзерлекнең барышы моны ачык күрсәтә. Чәчү орлыкларын туплау планы 50 процентка гына үтәлгән. Машиналарга ремонт ясау, кышкы агротехника чаралары бик акырын бара.

Делегатлар райкомны менә шуның өчен—авыл хуҗалыгына йомшак җитәкчелек итүе, үз карарларының үтәлешен тикшермәве өчен бик урынлы һәм җидди тәнкыйтьләделәр. Булган җитешсезлекләрне бетерү буенча эшлекле тәкдимнәр керттеләр. Конференция шулай ук тимер юл транспортына, комсомолга һәм җәмагать оешмаларына җитәкчелекне кискен рәвештә яхшыртуны таләп итте.

Конференция зур күтәренкелек белән үтте.

М. Хәмидуллин.

Сайлаулар хроникасы

Юдино районының партконференциясе үзенең эшен тәмам итте. Райком отчеты буенча фикер алышуларга язылган 47 делегаттан 31 кеше чыгып сөйләде. Ораторлар транспорт, промышленность һәм авыл хуҗалыгы эшләренә зур әһәмият бирделәр.

Конференция райкомның эшен канәгатьләнерлек дип тапты. Партиянең өлкә конференциясенә тавыш бирү хокукы белән 9 һәм киңәш бирү хокукы белән 3 делегат сайланды.

Райкомның беренче пленумында райком секретарьлары итеп Захаров, Кашаев һәм Маликов иптәшләр сайланды.

☙

Теләче районы коммунистларының отчет-сайлау җыелышы тәмам булды. Анда 117 член һәм 83 кандидат катнашты.

Җыелыш райкомның эшен канәгатьләнерлек дип тапты.

Ябык (яшрен) тавышка кую тәртибендә 21 кешедән райкомның яңа составы сайланды.

☙

Ширәмәт районының партконференциясе булып үтте. Райкомның эше канәгатьләнерлек дип табылды.

Райкомның яңа составына 21 член һәм 5 кандидат сайланды. Алар арасында „Прикамский“ совхозының стахановчы—тракторчысы Шаров, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашкан „Первый Шешминец“ колхозының стахановчысы Зюлина, СССР Верховный Советы депутаты Андриянова иптәшләр бар.

Пленум райкомның беренче секретаре итеп Марков, икенче секретарь итеп Новиков һәм кадрлар буенча секретарь итеп Тихонова иптәшләрне сайлады.

☙

Апас районының партконференциясе ябык (яшрен) тавышка кую тәртибендә райком пленумы составына 27 член һәм 5 кандидат сайлады. Шулардан 9 кеше райком пленумына беренче тапкыр сайланучылар.

Пленум райкомның беренче секретаре итеп Хәйруллин, икенче секретаре итеп Сөнгатуллин һәм кадрлар буенча секретарь итеп Әхмәдиев иптәшләрне сайлады.

☙

Партиянең **Норлат** райкомының беренче пленумы булды. Пленумда райком секретарьлары итеп Школдов, Шәмсеттинов һәм Яһудин иптәшләр сайланды.

☙

Кама Тамагы районының партконференциясе тәмам булды. Анда тавыш бирү хокукы белән 86 һәм киңәш бирү хокукы белән 14 делегат катнашты. Конференциягә беренче тапкыр делегат булып катнашучылар—49 кеше.

Конференция райкомның эшендәге кимчелекләрне кискен рәвештә тәнкыйтьләде. 1939 нчы елда район авыл хуҗалыгы өлкәсендә артта барды. Хәзер дә язгы чәчүгә хәзерлек эшләре канәгатьләнерлек түгел. Секретарь иптәш Фролова үзенең докладында, авыл хуҗалыгы эшендә артта калуның сәбәпләрен ачып салмады.

Конференция райкомның эшен канәгатьләнмәслек дип тапты.

Райком пленумы составына 25 кеше сайланды. Пленум райкомның беренче секретаре итеп иптәш Фәрдиевне сайлады.

☙

Партиянең **Ютазы** район конференциясенә тавыш бирү хокукы белән 65 һәм киңәш бирү хокукы белән 14 делегат катнашты.

Райком секретаре иптәш Гафиятуллин доклады буенча 34 кеше чыгып сөйләде.

Конференция райкомның эшен канәгатьләнерлек дип тапты. Ябык (яшрен) тавышка кую тәртибендә райком пленумы составына 23 член һәм 5 кандидат сайланды.

(ТатТАСС).

БЕЗНЕҢ ЭШТӘ КАЙБЕР БАШЛАНГЫЧ ТӘҖРИБӘЛӘР

Социалистик хуҗалыкның үсүе, халкыбызның материаль-көнкүреш хәле үсү җирле промышленность һәм промкооперация алдына зур таләпләр куя. Шуңа күрә дә җирле промышленностьның һәм промкооперациянең эшен яхшырту, аларны һәр яклап үстерү һәм киңәйтү, аларның эшен җирле рессурсларны тулысынча файдаланырлык итеп оештыру алда торган сугышчан бурычларның берсе булып санала.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды өченче бишьеллыкта җирле промышленность һәм промкооперация продукциясен эшләп чыгаруны кимендә ике тапкыр арттыру бурычын куйды. Бу бурычны уңышлы хәл итү хезмәт ияләре депутатларының шәһәр һәм район советларының, беренче чиратта, аларның җирле промышленность комиссияләренең эшенә бәйләнгән. Җирле советлар, аларның даими комиссияләре үзләре алдында торган бурычларны уңышлы рәвештә башкаруны тәэмин итү өчен көндәлек практик эштә һәрбер депутатның актив катнашуын булдырырга, үзләрен актив белән чолгап алырга тиешләр.

Хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советының җирле промышленность комиссиясе үзенең эшен комиссия алдында торган бурычларны җентекләп тикшерүдән башлап җибәрде. Без комиссиянең утырышларын ике тапкыр үткәрдек. Беренче утырышта комиссиянең бурычлары турындагы мәсьәләне җентекләп тикшердек һәм киң күләмдә фикер алыштык. Шуннан соң комиссиянең эш планы төзелде һәм ул икенче утырышта расланды.

Бу план буенча без күп кенә предприятиеләрдә, шул исәптән „Спартак“ һәм мех фабрикаларында чимал отходларыннан файдалану эшенең куелышын тикшерүне билгеләдек. Тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәсьәлә комиссиянең утырышында каралып, Шәһәр Советы башкарма комитетының җирле промышленность бүлеге белән берлектә, башкарма комитетының утырышына куелачак һәм без үзебезнең конкрет практик тәкдимнәребезне кертәчәкбез. Безнең эш планыбыз буенча кайбер предприятиеләрдә производство киңәшмәләренең эше белән танышу күздә тотыла.

Без үзебезнең эш тармагыбызда стахановчылык һәм күп станокчылар хәрәкәтенең торышын тирәнтен өйрәнүне, алдынгыларның тәҗрибәләрен киң популярлаштыруне үзебезнең төп бурычларыбызның берсе итеп куйдык. Комиссия алдында торган бурычларны уңышлы рәвештә хәл итү, билгеле, сайлаучылар белән элемтәне даими рәвештә ныгытуга, комиссияне актив белән чолгап ала белүгә бәйләнгән. Комиссиянең теге яки бу өлкәдә эшенең торышын тикшерүгә багышланган күчмә утырышлары сайлаучылар белән, массалар белән элемтәнең иң яхшы формаларыннан берсе булып тора. Алар предприятиеләрдә эшләүче барлык депутатларның һәм производство алдынгыларының — стахановчыларның, күп станокчыларның катнашы белән үткәрелгән вакытта, һич шиксез, уңышлы нәтиҗәләр бирәчәкләр. Менә шуңа күрә дә без комиссиянең күчмә утырышларын предприятиеләрдә әледән-әле үткәрәчәкбез.

Без шулай ук Шәһәр Советы башкарма комитетының җирле промышленность бүлегенең эшенә контроль буенча да күп кенә практик чаралар билгеләдек һәм алар хәзер тормышка ашырылып бара инде.

Безнең эштә булган кайбер башлангыч тәҗрибәләр шундый. Без, депутатлар, сайлаучыларыбызның ышанычын аклау өчен армый-талмый эшләрбез. Җирле промышленность комиссиясе үзенең мактаулы һәм җаваплы бурычларын намус белән үтәр.

Ш. Низамутдинов.

Хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советының җирле промышленность комиссиясе председателе.

8 нче МАРТ

КЛАВДИЯ НИКОЛАЕВА

8 нче Март — Халыкара Коммунистик Хатын-Кызлар Көне— революцион көрәш тарихына күренекле дата булып керде.

Бу көнне Коммунистик Интернационал, Маркс—Энгельс—Ленин—Сталин байрагы астында, бөтен дөньядагы хезмәт иясе хатын-кызларның, социалистик революция өчен көрәшкә, изелгән кешелек дөньясын азат итү өчен революцион көрәшкә, империализмга һәм сугышка каршы көрәшкә хәзерлекләренә смотр үткәрә.

Безнең илдә бу көн—хатын-кызларны азат итү бәйрәме.

Совет хатын-кызлары яулап алынган җиңүләргә ел саен 8 нче Мартта йомгак ясыйлар һәм коммунизм төзелеше буенча, илнең оборонасын ныгыту буенча партиябез һәм хөкүмәтебез куйган бурычларны үтәүгә үзләренең көчләрен тагын да ныграк туплыйлар.

Үткән ел—аеруча гүзәл ел булды. Үткән ел Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясенең XVIII нче съезды булып үтте. Бу съездда юлбашчыбыз һәм остазыбыз иптәш Сталин капиталистик илләрдә яшәп килә торган каршылыкларны гаять тирәнтен һәм даһилык белән ачты, социалистик строебызның җиңүләре бөеклеген күрсәтте, коммунизм өчен алдагы көрәшнең сугышчан яңа программасын бирде.

Партиябезнең һәм Совет хөкүмәтенең Сталинчыл даһи политикасы Көнбатыш Украинадагы һәм Көнбатыш Белоруссиядәге кардәш халыкларны паннар Польшасы изүеннән азат итүне һәм аларны Украина ССР һәм Белоруссия ССР халыклары белән кушуны тәэмин итте.

Социализм илендә хатын-кыз—җәмгыятьнең тулы хокуклы члены, коммунизм өчен көрәшче һәм аны төзүче, политик, җәмагать һәм культура тормышында актив катнашучы.

Илебездә социалистик революциянең һәм коммунизм төзелешенең бөек бурычларын хәл иткәндә, Ленин һәм Сталин коммунистик җәмгыять өчен көрәштә эшче һәм крестьян хатын-кызлары уйнарга тиеш булган гаять зур рольне һәр вакыт күрсәттеләр.

Безнең көрәшебезнең иң гүзәл йомгагы—Сталин Конституциясе. Бу Конституциядә социализмның СССР хезмәт ияләре ирешкән бөек җиңүләре закон белән ныгытылганнар.

Хатын-кызларның тәмам азат ителүе, аларга ирләр белән тигез хокуклар бирелү—бу җиңүләрнең берсе. Безнең Советлар Союзында эзлекле социалистик демократия тормышка ашырылды, хатын-кызлар барлык хезмәт ияләре белән берлектә җәмагать эшләрендә һәм дәүләтне идарә итүдә катнашалар.

Һәр төрле азатлык хәрәкәтләренең һәм революцияләрнең вәкилләре уннарча, хәтта йөзләрчә еллар буе хатын-кызларның тигез хокуклары турында таләпләр куеп килделәр. Ләкин җир шарының алтыдан биш өлешендә—капитализм һәм буржуазия өстенлек итә торган урыннарда хатын-кызларның хокуксызлыгы бетерелмәде.

Капиталистик илләрдә хезмәт иясе хатын-кызларны иң рәхимсез төстә эксплоатациялиләр. Мәсәлән, Англиядә эшче хатын-кызларга ирләр белән бер тигез хезмәт өчен хезмәт хакын ирләргә түләнгәнгә чагыштырганда 60 процент кына түлиләр. Франциядә тукучы хатын-кызларның хезмәт хакы кризис елларында 40 процент кимеде.

Англиянең һәм Франциянең империалист ерткычлары тарафыннан Европада башланган сугыш хезмәт иясе хатын-кызлар массасының аннан башка да авыр хәлен тагын да начарландырды. Фронтка җибәрелгән эшчеләрнең һәм крестьяннарның миллионнарча семьяләре үзләрен туйдыручылардан мәхрүм калдылар һәм ачлыкка дучар ителделәр. Йөз меңнәрчә хатын-кызларны һәм балаларны ирексезләп эвакуацияләү, кыйммәтчелекнең үсүе, налогларның артуы, туклану продуктларының җитешмәве, капиталистик эксплоатациянең көчәюе—болар барсы да хатын-кызлар җилкәсенә авыр йөк булып төште.

Англиядә капиталистлар, сары профсоюзлар белән берлектә, хезмәт ияләренең тормыш дәрәҗәләренә һәм хокукларына яңа һөҗүм ясыйлар. Халыкара Коммунистик Хатын-Кызлар Көненә хәзерләнгәндә, Англиянең коммунистлар партиясе хезмәт хакын күтәрү, армиягә алынучыларның семьяләренә пособиеләрне арттыру һәм башка лозунглар астында бу көндә массовый демонстрацияләр үткәрергә чакыра.

Капиталистик илләрдә хезмәт иясе хатын-кызларның тормышы авыр һәм караңгы. Буржуазия аларны хәтта хезмәт иясе ирләргә бирелә торган кечкенә генә „хокуклар“дан да мәхрүм итте.

Бөтенсоюз Советларының Гадәттән тыш VIII нче съездында иптәш Сталин, буржуаз конституцияләр турында сөйләп, болай диде: „Алар гражданнарның тигез хокуклары турында сөйлиләр, ләкин шунда ук, бу, хатын-кызларга кагылмый, яисә аларга бер кадәр генә кагыла, дигән искәрмә ясыйлар“.

Капиталистик илләрнең берсе дә хатын-кызларның тигез хокуклары һәм аларны азат итү бурычын бер вакытта да хәл итмәс. Бу бурычны бары тик бөек Октябрь Социалистик революциясе, бары тик бөек Ленин—Сталин партиясе хәл итә ала иде һәм хәл итте.

Большевиклар партиясе һәм Совет власте халык арасыннан йөз меңнәрчә хатын-кызларны дәүләт, партия, хуҗалык һәм профсоюз эшенә җитәкче урыннарга күтәрделәр. Безнең социалистик парламентыбызда—СССР Верховный Советында—хатын-кызлардан 189 депутат бар. Союзный һәм автономияле социалистик республикаларның Верховный Советларында хатын-кызлардан 1.436 депутат бар, ә хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына хатын-кызлардан 422.279 кеше сайланды.

Җирле Советлар—Совет властеның халыкка иң якын органнары. Промышленностьның һәм авыл хуҗалыгының тагын да үсүе генә түгел, бәлки магазиннарның, ашханәләрнең, мунчаларның, кер юу урыннарының, больницаларның, балалар учреждениеләренең, мәктәпләрнең, клубларның хәле, торак йортларының төзеклеге, урамнарның чисталыгы да аларның эшләренә бәйләнгән. Сталинчыл өченче бишьеллык планы һәм партиябезнең, хөкүмәтебезнең барлык заданиеләрен уңышлы үтәү җирле Советларның эшенә бәйләнгән.

Җирле Советларда актив эшләп, хатын-кызлар гаять зур дәүләт эше башкаралар.

Хатын-кызларның киң массасы илнең җәмагать оешмаларында катнаша. 9 миллионнан артык хатын-кыз профсоюз членнары булып торалар, 400 меңнән артык хатын-кыз профсоюзларның үзәк, край, өлкә комитетларының, фабрика-завод комитетларының һәм җирле комитетларының пленум членнары итеп сайландылар. Хатын-кызлар производствода хезмәтне яхшы оештыру өчен, ныклы хезмәт дисциплинасы өчен, эш нормаларын арттырып үтәү, хезмәтнең югары җитештерүчәнлеге, культура-көнкүреш хезмәте күрсәтүне яхшы оештыру өчен көрәшәләр.

Сталинчыл бишьеллыклар елларында эшче һәм хезмәткәр хатын-кызлар саны бик нык үсте. 1932 нче елда бөтен халык хуҗалыгында хатын-кызлардан 6 миллион 7 мең кеше (барлык эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең 27,4 проценты) эшләгән булса, 1939 нчы елны инде аларның саны 10 миллион 773 меңгә (37,4 процентка) җитә. СССР да хатын-кызлар промышленностьның һәм авыл хуҗалыгының барлык тармакларында диярлек хезмәт итә алалар һәм итәләр. Үзләренең җитештерүчән эшләре белән хатын-кызлар ирләрдән аз гына да калышмыйлар һәм үзләренең хезмәтләре өчен алар белән бер тигез хезмәт хакы алалар.

Совет строе социалистик хезмәттә, Социалистик Ватанга һәм коммунизм эшенә чын күңелдән бирелгәнлектә гүзәл үрнәкләр күрсәтүче йөз меңнәрчә хатын-кызларны күтәрде һәм тәрбияләде. Үзләренең героик хезмәтләре белән, үзләренең батырлыклары белән халык массасының мәхәббәтен казанган һәм хөкүмәттән бөек бүләкләр алган алдынгы хатын-кызларның саны елдан-ел үсә.

Бездә хезмәт—намус эше, дан эше, батырлык һәм геройлык эше. Совет хатын-кызлары кайда гына эшләмәсеннәр, алар үзләренең квалификацияләрен күтәрергә, производство техникасын үзләштерергә тырышалар. Совет хатын-кызлары алдында киң юл ачылган. Бездә Советлар Союзы Геройлары булган хатын-кызлар бар. Безнең промышленностыбызда хатын-кызлардан 100 меңнән артык инженерлар һәм техниклар эшли: хатын-кызлардан 12 мең ярым кеше фәнни работник булып эшли. Алар арасында СССР фәннәр Академиясенең членнары һәм член-корреспондентлары бар. Кыска гына вакыт эчендә дәүләт һәм партия эшендә җитәкчелеккә күтәрелүчеләрнең гомуми санынан 20 проценты хатын-кызлар.

1940 нчы ел—Сталинчыл өченче бишьеллыкның өченче елы—безгә социализмның бөтен дөнья күләмендә тарихи әһәмиятле яңа җиңүләрен китерә. СССР сыйныфсыз социалистик җәмгыять төзелешен тәгәлләү һәм социализмнан коммунизмга тезмәле рәвештә күчү полосасына керде.

Бу ел хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да күтәрү өчен, Ватаныбызның оборона куәтен тагын да ныгыту өчен, совет халкының социалистик культурасының һәм материаль хәле яхшыруның яңа күтәрелеше өчен көрәшне тагын да ныграк җәелдерү елы булыр. Бу бөек көрәштә совет хатын-кызларына мактаулы урын бирелгән.

(Ахры киләсе номерда).

1940 нчы ЕЛ НАВИГАЦИЯСЕН ҮРНӘК РӘВЕШТӘ КАРШЫЛЫЙК

ҮТӘЛМӘГӘН ПЛАННАР ҺӘМ КҮЗ БУЯУЧЫ ҖИТӘКЧЕЛӘР ТУРЫНДА

Югары Волга елга пароходчылыгында пристань начальникларының киңәшмәсе булды. Киңәшмәдә пристаньнәрнең 1940 нчы ел навигациясенә хәзерлек мәсьәләләре тикшерелде. Казан пристане начальнигы иптәш Орлов механизмнарга ремонт ясау эшенең яхшы баруы турында сөйләде.

Бу киңәшмәдән соң күп тә үтмәде, Югары Волга елга пароходчылыгы буенча махсус приказ чыкты. Бу приказда Казан пристаненең механика мастерское алдынгылар сафына кертелә. Механизация эшләре буенча баш инженер иптәш Захватов мастерскойның алдынгылыгы өчен, ремонт планын яхшы үтәве өчен 500 сум акча белән бүләкләнә.

Казан пристаненең механика мастерское чынлап та яхшы эшлиме, механизмнарга ремонт ясау планын чынлап та арттырып үтиме? Юк, арттырып үтәми. Февраль аенда бу „арттырып үтәү“ нең сере ачыла башлады. Баш инженер иптәш Захватов пристань начальнигына һәм Югары Волга елга пароходчылыгына биргән маглүматларында транспортерларга ремонт ясау планының үтәлешен күпертеп күрсәткән, күз буяу юлына баскан. Фактта исә 2 транспортерга ремонт ясау эше төгәлләнмәгән. Моторларга агымдагы ремонт ясау эшләренә киткән 476 сәгат вакыт капиталь ремонт ясау сәгатьләреннән алып өстәлгән. Шулай итеп, агымдагы ремонт планының проценты ясалма рәвештә күтәрелгән.

Транспортерларга ремонт ясау буенча хәзер дә әле үзгәреш юк.

Пристаньдә 1940 нчы елның навигациясенә хәзерлек эшләре план буенча бармый. Механизмнарга ремонт ясау буенча алдан тиешле ведомостьлар төзелмәгән, материаллар һәм детальләр хәзерләнмәгән. Судноларга ремонт ясау заводлары белән элемтә бик йомшак.

Пристаньдә үзләренең үрнәкле эшләре белән, хезмәт җитештерүчәнлеген бер туктаусыз күтәрә барулары белән танылган стахановчылар аз түгел. Мәсәлән, Шәһәр Советы депутаты иптәш Зиннәтуллин айлык планны системалы рәвештә 170—175 процент итеп үти. Слесарь иптәш Гыйсматуллин айлык планны 140 процент һәм иптәш Димитряков 190 процент итеп үтиләр. Ремонт эшендәге менә бу алдынгы иптәшләрнең тәҗрибәләрен өйрәнү һәм уртаклашу буенча пристань җитәкчеләре һич җитәрлек шөгылләнмиләр.

Механизмнарга үз вактында һәм югары сыйфатлы итеп ремонт ясау йөк төяү һәм бушату эшләренең уңышын хәл итә. Пристань җитәкчеләре навигациягә хәзерлекнең менә бу тармагына аеруча игтибар итәргә тиешләр.

Складларга ремонт ясау планы да үтәлми. Аларның түбәләрен ябу өчен 4.800 квадрат метр толь шушы көнгә кадәр хәзерләнмәгән. 43 данә бризентның 3се генә эшкә яраклы. 10 данә үлчәү механизмы җитешми. Вокзалга ремонт ясау планы бары 15 процентка гына үтәлгән.

Навигациягә хәзерлекнең менә бу күңелсез яклары, ни өчендер, пристань җитәкчеләрен борчымый. Алар үтәлмәгән планны үтәлде дип күрсәтәләр, күз буяу юлына басалар. Бу тәртипсезлеккә ашыгыч рәвештә чик куелырга тиеш.

Ф. Исхаков.

РАЦИОНАЛИЗАТОРЛЫК ЭШЕНӘ ИГТИБАРНЫ КӨЧӘЙТИК

Язу машиналары заводы стахановчылары һәм инженер-техник работниклары уйлап табу һәм рационализация тәкдимнәре кертүдә зур активлык күрсәтәләр. Алар үткән елны гына да заводка барлыгы 202 тәкдим бирделәр. Шулардан 55 ен тормышка ашыру нәтиҗәсендә 46 мең сумга якын экономия алынды.

Ләкин завод һәм цех җитәкчеләре бу әһәмиятле эшкә тиешле игтибарны биреп җиткермиләр. Бирелгән тәкдимнәр вактында тикшерелми, кабул ителгәннәре үз вактында тормышка ашырылмый. Моның шулай икәнлеген ачыкландыру өчен берничә факт китерү дә җитә.

1939 нчы елны бу өлкәдә планлы эш алып барылмады, тематик план төзелмәде. Шундый аянычлы хәл быел да дәвам итә. Алдынгы фабрика һәм заводларның бу өлкәдә булган уңышлы тәҗрибәләре белән уртаклашу эше оештырылмады. Шулар нәтиҗәсендә, рационализатор Беспалов, Стрекалов, Ястребов, Ипатов, Ильин, Лисицин һәм Воробьев иптәшләрнең кыйммәтле һәм гаять әһәмиятле тәкдимнәре берничә еллардан бирле хәрәкәтсез яткырылалар.

Заводның алдынгы кешеләре—рационализаторлар 1940 нчы елда уйлап табу һәм рационализация тәкдимнәреннән 100 мең сум экономия алуга ирешү йөкләмәсе алганнар иде. Заводның партия, профсоюз һәм хуҗалык оешмалары бу йөкләмәне үтәү өчен тиешле булышлыкны күрсәтмиләр әле.

Г. Кушаев, Ә. Урманчиев.

ТЕХНИК КУЛЬТУРАЛАРГА ҖАВАПСЫЗ КАРАШ

Тымытык районында үткән ел 2.317 гектар техник культуралар чәчелгән. Шуның 1.280 гектары кудряш җитен.

Бу райондагы Ык, Стәрле, Мәллә елгасы буйларында җитен, киндер кебек культураларны игү өчен туфрак гаять яхшы. Чәчү, тәрбияләү һәм эшкәртү эшләрен агротехника кагыйдәләренә төгәл туры китереп башкарганда, бу культуралардан мул уңыш алырга була. Ә фактта исә эш бөтенләй киресенчә тора.

Үткән ел район буенча җитен орлыгы уңышы һәр гектардан уртача 1,3 центнер, киндер 0,30 центнер һәм көнбагыш бары 1,43 центнер гына алынган. Сүс уңышының күпме булуы турында районда учет та юк.

Берничә еллардан бирле бу район техник культура орлыкларын ел саен дәүләттән алып килә. Ә алган ссудаларны кайтару бер елны да тулысынча үтәлмәгән. Шулай ук районда техник культуралар буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәмәү дә гадәт булып киткән. Үткән ел дәүләткә көнбагыш тапшыру планы бары 46,4 процент һәм контрактация буенча җитен орлыгы тапшыру бары 50 процент кына үтәлгән.

Техник культуралар буенча начар уңыш алуның, дәүләт алдындагы йөкләмәләрне үтәмәүнең һәм дәүләттән ел саен ссудалар алып та, аны вактында кайтармауның сәбәпләрен ерактан эзлисе юк. Моның өчен Тымытык һәм Тельман исемендәге колхозларда техник культураларга җавапсыз караш фактларын күрсәтү дә җитә.

Тельман исемендәге колхозда үткән ел 80 гектар җитен, 12 гектар киндер һәм 70 гектар көнбагыш чәчелгән. Колхозда язгы чәчүгә 20 нче апрельдә чыкканнар. Ә көнбагыш һәм җитен культураларын чәчү эшенә бары 4—5 нче майда гына керешкәннәр һәм бу культураларны чәчүне 13—14 көнгә сузганнар. Техник культуралар чәчелгән мәйданга бер төрле дә ашлама кертелмәгән. Тукландыру, мульчировать итү, үсемлек корткычларына һәм чүп үләннәренә каршы көрәш үткәрелмәгән. Җитен һәм киндер культураларын эшкәртүдә җавапсызлыкка һәм әрәм-шәрәм итүгә ачыктан-ачык юл куелган. 1938 нче елда 31 гектардан чыккан киндер сабагын чертккәннәр. 18 гектар җитен сабагы сугылмыйча кырда калган. Үткән елда 12 гектардан алынган баса һәм киндер сабагы чылатуга салынмыйча яланда калган. Җитен һәм киндер буенча даими звенолар оештырылмаган. Бу культураларны игүгә икенче чираттагы эш итеп каралган һәм очраклы кешеләргә тапшырылган.

Бу хәл районның башка колхозларында да шулай. Бер генә колхозда да даими звенолар юк.

Тельман исемендәге колхозда быел 80 гектар җитен, 70 гектар көнбагыш һәм 12 гектар киндер чәчү билгеләнгән. Ләкин чәчү өчен колхозның киндер орлыгы бөтенләй юк. Шулай ук җитен һәм көнбагыш культуралары да ярты мәйданны капларга да җитәрлек түгел.

Тымытык колхозында да техник культуралар мәйданына ашламалар кертү, мульчировать итү, тукландыру кебек эшләр белән бөтенләй шөгылләнмәгәннәр. 1938 нче елда баса һәм киндер саламын вактында талкымыйча черткәннәр. Үткән елгы 8 гектардан алынган киндер саламы басуда кар астында калган һәм 82 гектар җитеннең саламы эшкәртелмәгән килеш өеп куелган. Шулай булгач бу колхозның үткән ел техник культуралардан сметада каралган 19 мең сум доход урынына бары 129 сум гына алуына һәм быел техник культураларны чәчү орлыгы булмавына гаҗәпләнергә урын калмый.

Район оешмалары ни өчендер, бу зур җитешсезлекләргә тыныч кына карыйлар. Алар, техник культураларга карата агротехника кагыйдәләрен үтәмәүне, бу культуралардан алынган уңышны әрәм-шәрәм итүне һәм системалы рәвештә дәүләт йөкләмәләрен үтәүнең өзелүен нормаль хәл итеп исәплиләр күрәсең! Техник культураларга җавапсыз карашның дәвам итүе быелгы язгы чәчүгә хәзерлек эшләрендә дә нык сизелә. Колхозларда техник культуралар чәчеләчәк участкыларга кертү өчен ашламалар хәзерләү, чәчү орлыгы туплау һәм аны чәчүгә яраклы кондициягә җиткерү, бу культураларны җитештерү буенча даими звенолар оештыру эшләре үз агымына куелган.

Ниһаять, техник культуралар уңышын күтәрүнең илнең оборонасын ныгытуда һәм киң куллану товарларын җитештерүдә никадәр әһәмиятле урын тотуын Тымытык район җитәкчеләренә аңларга вакыт.

А. Вәлиев.



„Красный Восток“ совхозында (Алексеевский районы) язгы чәчүгә хәзерлек. РӘСЕМДӘ: кырчылык бригадалары арасында төзелгән социалистик ярыш договорына бригадир иптәш П. И. Горохов кул куя.

С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Яшелчәдән мул уңыш алу өчен

Безнең яшелчәчелек бригадасы үткән ел һәр гектардан уртача 205 центнер кишер, 300 центнер чөгендер һәм 462 центнер кәбестә уңышы алды.

Без быел һәр гектардан уртача 400 центнер чөгендер, 350 центнер кишер, 450 центнер кәбестә, 250 центнер помидор һәм 250 центнер суган уңышы алуга ирешү турында йөкләмә алдык.

Алган йөкләмәләрне үтәү өчен хәзер бригадада практик чаралар күрелә. Орлык хәзерләүне тәмам иттек. Яшелчә утыртылачак 14 гектар мәйданда 6 басулы чәчү әйләнешен планлаштырдык. Бу мәйданның һәрбер гектарына 100 йөк тирес чыгардык. Кар тоту үткәрдек. Тотылган карның тирәнлеге 1—1,5 метрга җитә.

Бригада членнары барсы да агротехниканы өйрәнү түгәрәкләрендә укыйлар.

Ә. Сәүбанов.

Әлмәт районы „Элком“ колхозының яшелчәчелек бригадиры.

Чит илләрдә

Сугышның беренче ярты елының йомгаклары турында Германиянең информация бюросы

БЕРЛИН, 2 март. (ТАСС). Германиянең информация бюросы түбәндәге хәбәрне тапшыра:

„АКШ ның дәүләт секретаре урынбасары Уэллес Берлингә сугышның икенче ярты елының нак беренче көнендә, ягни сугышның үткән чорына йомгаклар ясарга мөмкин булган көнне килде. Германиянең политик даирәләрендә сугышның барышыннан канәгатьләнү белдерү өчен бөтен нигезләр бар дип саныйлар. Лондонда һәм Парижда исә сугышның болай баруын һич тә көтмәгәннәр иде. Англия һәм Франция Германиягә сугыш иглан иттеләр. Шуннан соң алар Гитлерның солых тәкдимен тупас рәвештә кире кактылар. Шулай итеп, сугыш җиңгәнгә кадәр, ягни Германиягә аның яшәвен тәмам тәэмин иткәнгә һәм диңгезләр ирке урнаштырылуга кадәр дәвам итәчәк. Бу хәл шуңа китерәчәк ки, Англия плутократиясе хәзерге сугыштан соң башка халыкларның яшәвенә куркыныч тудырмаячак. Сугышка кыска гына итеп түбәндәгечә йомгак ясарга мөмкин: беренчедән, Англия һәм Франция Германияне экономик яктан да, сугыш ягыннан да җиңә алмаячакларын беләләр; икенчедән, Англия Германияне нинди хәлгә куярга теләгән булса, халыкара хокукны бозучы Англиянең блокадасына каршы Германиянең җавап чаралары Англияне нак әнә шундый хәлгә куялар. Дошман флотының югалтулары турындагы саннар моны бик ачык күрсәтәләр; өченчедән, Германиянең кораллы көчләре тулы хәзерлек хәлендә торалар һәм хәл иткеч удар ясау турында приказ гына көтәләр. Аның срокларын бер кем дә белми, ләкин бу ударның һичбер күтелмәгән дәрәҗәдә көчле булачагына һәр кем ышана ала“.

Аннары белдерүдә әйтелүенчә, Англиянең хәле ышанычсызрак була барган саен аның нейтраль илләрне сугышка тарту юлы белән Германиягә каршы ике фронтта сугыш оештырырга маташуы көчәйгәннән-көчәя бара. Белдерүдә болай диелә:

„Хәтта Англия кайбер нейтраль илләрне үз ягына тарта алса да, аның исәбендә ялгышуы мөмкин, чөнки теге яки бу нейтраль илнең ярдәме нәтиҗәсендә Англия алачак нәрсәне Советлар Союзы белән дуслык нәтиҗәсендә Германия алган отыш белән һич тә тиңләштереп булмый“.

Белдерү түбәндәге сүзләр белән тәмам була:

„Үзенең сугыш ягыннан өстенлеген һәм экономик яктан көчлелеген аңлап, Германия сугышның икенче ярты елына кергәндә шундый мәсьәләне хәл итү алдында тора ки, моны Германиядә генә түгел, бәлки Европадагы һәм бигрәк тә Италиядәге барлык яшь халыклар түземсезлек белән көтәләр“.

ФРАНЦИЯДӘ ҺӘМ БЕЛЬГИЯДӘ КОММУНИСТЛАРНЫ ЭЗӘРЛЕКЛӘҮ

БРЮССЕЛЬ, 2 март. (ТАСС). Хәбәр итүләренә караганда, Арраста (Франция) тимер юлчылар профсоюзы секретаре Делуазон һәм казначей Краммер „коммунистик пропаганда“да гаепләнеп ел ярымга төрмәгә һәм штрафка хөкем ителгәннәр.

Боринаж күмер бассейнында (Бельгия) полиция облава ясаган. Монста да күп кенә кешеләр кулга алынган. Монс интеллигенциясе арасында тентүләр ясалган. Газеталарның язуына караганда, кулга алуларга да карамастан, „коммунистларның актив эше дәвам итә“.

Төркиянең баш министре Сайдамның речь

ӘНКАРА, 2 март. (ТАСС). Анатоли телеграф агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Төркиянең баш министре Сайдам 29 нчы февральдә кич белән речь сөйләгән. Речь радио буенча тапшырылган. Агентлык болай дип хәбәр итә:

„Үзенең речендә Сайдам милли оборона турындагы законны гамәлгә кертү турында, шулай ук шул закон уңае белән Төркиягә карата нигезсез хәбәрләр йөрү турында сөйләде. Төркиянең баш министре бу законның илне экономик яктан да, шулай ук милли-оборона ягыннан да саклауга юнәлдерелгән кискен чаралар күрүне күздә тотканлыгын искә төшереп үтте. Сайдам хөкүмәтнең бу чараларга бары тик бик кирәк булган хәлләрдә генә барачагын әйтте. Шулай итеп, ул, имештер, бу законны кертү мобилизация башлану алды булу турында чит илләрдә таратыла торган хәбәрләрне, шулай ук хөкүмәтнең имештер сугышка керешергә карар биргәнлеге турында ил эчендә таралган хәбәрләрне кире какты“.

Бу хәбәрләрнең уйдырма (тенденция) икәнлеге турында халыкны кисәтеп, Сайдам тышкы политик хәлгә анализ ясауга күчте. Ул болай диде:

„Соңгы вакытта илдә һәм чит илләрдә Европадагы сугышның перспективалары турында агентлыкларның төрле хәбәрләре уңае белән төрлечә фикерләр әйтелде. Болардан тыш хәзерге вакыйгаларнең нииндидер яңа вакыйгаларга китерергә мөмкинлеге турында нигезсез хәбәрләр таратылды. Күп кенә вакыйгаларнең безнең СССР белән мөнәсәбәтләребезгә бәйле булуы турында фикерләр күтәрелде һәм мин югарыда әйткән сәбәпләр буенча милли оборона законын кертүне шушы барлык информацияләргә бәйлиләр иде.

Безнең СССР белән мөнәсәбәтләребездә соңгы 6 ай эчендә бер нәрсә дә үзгәрмәде. Без яши торган чорда һәр кем үзенең уйларын яшерә. Мондый вакытта үзеннән башка бер кемгә дә ышанырга ярамый,—ләкин мин бу турыда кыюлык белән әйтәм. Без бер кайчан да СССР га каршы юнәлдерелгән нинди дә булса хәрәкәт ягында булмадык. Хәер, бездән моны бер кем дә таләп тә итми. СССР турыдан-туры безгә каршы юнәлдерелгән хәрәкәткә барачакмы? Мондый ихтимал бар дип уйларга мөмкинлек бирә торган бер нәрсә дә хәзергә кадәр юк. Димәк, күрәсез, безнең белән СССР арасында имештер инцидент булган дигән хәбәрләрнең, соңгы көннәрдә көчәеп киткән хәбәрләрнең бер нинди нигезләре юк һәм алар уйдырма (тенденция) хәбәрләр генә. Җәмагат фикеренә йогынты ясау өчен төрле юллар белән таратыла торган бу хәбәрләрнең Төркия политикасына кагылганда үзләренә юлны бик кыенлык белән генә табачагына без ышанабыз“.

Аннары баш министр Төркия политикасының үзгәрешсез икәнлеген һәм аның бер нинди дә серле яки ачык булмаган ягы юклыкны күрсәтеп үтте. Ул болай диде:

„Безнең йөкләмәләребез ачык. Безнең теләкләребез һәм максатларыбыз билгеле. Без үзебезнең куркынычсызлыгыбызны һәр кемгә маглүм булган договорлар белән билгеләдек. Без үзебездә ышанмаучылык атмосферасы кайчан булачакны әйттек һәм ачык күрсәттек. Безнең „сугыштан тыш“ булу позициябез милли кагылгысызлыгыбызга таяна. Бу позиция нинди дә булса комбинацияләрнең уенчыгы түгел һәм киләчәктә дә булмас“.

Балалар иҗадының Бөтенсоюз олимпиадасы

ВЛКСМ Үзәк Комитетының X нчы пленумы, балалар иҗадын киңәйтүгә гаять зур политик әһәмият биреп, 1940 нчы елда балалар иҗадының Бөтенсоюз олимпиадасын үткәрү турында карар кабул итте.

Олимпиадага хәзерлек комсомолны мәктәпкә якынайтырга, өлгерешне күтәрергә һәм укучы балалар арасында аңлы дисциплинаны ныгытуга булышлык итәргә тиеш. Олимпиадага хәзерлекне мәктәптән башларга кирәк. Балалар иҗадының Бөтенсоюз олимпиадасына катнашу хокукын алу өчен классларда, отрядларда, түгәрәкләрдә социалистик ярышны — коллектив һәм индивидуаль ярышны хәзердән үк киң оештырырга кирәк.

Укучыларның бөтен массасын үзешчәнлек белән чолгап алу, түгәрәкләрнең саннарын арттыру, бу түгәрәкләргә балаларның яңа группаларын тарту олимпиадага хәзерлектә төп бурычларның берсе булып тора. Олимпиадага катнашучылар алдына иҗади эшне мәктәптә уңышлы укуга ирешү белән бергә бәйләп алып бару бурычы куела.

Балалар иҗадының Бөтенсоюз олимпиадасында катнашучыларны сайлап алу теләге белән балалар иҗадының смотрлары апрельдә — районнарда һәм июльдә — республика күләмендә үткәреләчәк.

Комсомол оешмалары һәм халык мәгарифе органнары бу мөһим чарага хәзерлек эшләрен киң җәелдерергә тиешләр иде. Ләкин практик эштә бу күренми әле. ВЛКСМ ның күп кенә райкомнары балалар үзешчәнлеген җәелдерүгә игтибарны көчәйтү кирәклеге турында ВЛКСМ Үзәк Комитетының X нчы пленумы таләпләрен аңламаганнар һәм олимпиадага хәзерлек эшеннән читләшкәннәр. ВЛКСМ ның Питрәч, Арча, Тәтеш райкомнары моңа конкрет мисаль булып торалар. Алар олимпиадага хәзерлек буенча бер нәрсә дә эшләмәгәннәр.

ВЛКСМ ның Чистай райкомы һәм аның секретаре иптәш Баринов та олимпиадага хәзерлек эшен начар оештыра. Биредә олимпиадага хәзерлек эшенә балалар тартылмаган. Пионерлар клубын район смотрына хәзерлек эшен алып баруда файдалану урнына, аны ремонтка япканнар, ләкин ремонт эшләре дә ай буена үткәрелми торган. Чистай театры артистларыннан кайберәүләр олимпиадага хәзерлек эшенә катнашырга телиләр. Шуңа карамастан, райкомол секретаре иптәш Баринов та, шулай ук, РОНО мөдире иптәш Юсупов та ни өчендер бу көчтән файдаланмыйлар.

Олимпиадага хәзерлек эше Казан шәһәрендә аеруча начар тора. Комсомолның Шәһәр Комитеты оператив җитәкчелек итми. Киров райкомолының секретаре иптәш Курасов һәм райкомның мәктәп балалары һәм пионерлар бүлеге мөдире иптәш Логутченко районда олимпиадага хәзерлекнең нинди хәлдә торуын да белмиләр.

Олимпиадага хәзерлек эшенең торышы начар булуының сәбәбен ВЛКСМ райкомнарының һәм халык мәгарифе органнарының бу әһәмиятле эшкә җитәкчелек итмәүләреннән һәм балаларның үзешчәнлекләренә тиешле игтибар бирмәүләреннән эзләргә кирәк.

Совет балалары арасында талантлы балалар, матур биючеләр, җырлаучылар күп. Яшь талантларның иҗадлары сәнгатьнең барлык өлкәләренә дә үтеп керәләр. Мәктәпләрдә, клубларда меңнәрчә художество үзешчәнлек түгәрәкләре эшли. Күп кенә түгәрәкләр яхшы уңышлар да казандылар. Киров районындагы 10 нчы мәктәбендә география укытучы иптәш В. Ф. Логутова җитәкчелегендәге опера түгәрәге „Черевички“ операсын хәзерләде. 24 нче мәктәпнең X нчы классында укучы Валя Трофимова җитәкчелегендәге җырлар һәм бию ансамбле яхшы гына эшләп килә.

Кайбер иптәшләрдә үзешчәнлек түгәрәкләрендә актив катнашу яхшы өлгерешкә ирешүдә укучыга комачаулык китерер дигән караш яшәп килә. Мондый караш, һич шиксез, дөрес караш түгел. Моны конкрет фактлар үзләре юкка чыгаралар. Менә укучылардан Виля Шлефман (2 нче мәктәп), Ира Балаева (41 нче мәктәп), Галия Рәхмәтуллина (2 нче мәктәп) Казан Пионерлар йортындагы үзешчәнлек түгәрәкләренең берничә еллар буена актив катнашучылары булып торалар. Шул ук вакытта алар укудан да һәм дисциплинадан да отличниклар. Яки Юрий Ивановны (6 нчы мәктәп) алыйк. Пионерлар йортына актив эшкә тартылганнан соң ул, уку сыйфатын да күп яхшыртты. Мондый фактларны күп китерергә мөмкин. Смотрга хәзерлек эше отличникларның эшләрен яхшыртуга, өлгерешне күтәрүгә һәм бер класста ике ел утыруны бетерүгә юнәлдерелергә тиеш.

Комсомолның район комитетлары һәм халык мәгарифе органнары бу әһәмиятле эшкә җитәкчелекне тамырыннан яхшыртырга, смотрны отлично үткәрерлек чараларны тиз арада эшләргә тиешләр. Режиссерлар, артистлар, драматурглар, композиторлар, язучылар бу эштә комсомол оешмаларына җидди булышлык күрсәтергә һәм мәктәпкә, клубка, балаларның үзешчәнлек түгәрәкләренә килеп, яхшы уңышларга ирешү өчен ярдәм итәргә бурычлылар.

Казан шәһәрендәге сәнгать көчләреннән мәктәпләребезгә кирәк ярдәмне без аеруча көтәбез. Балалар үзешчәнлекләренә ярдәм күрсәтү турында ТАССР халык артисты иптәш Любинның, ТАССР ның атказанган артисткасы иптәш Кадминаның чакырулары сәнгать работниклары арасында киң отклик алыр.

А. Перов.

ВЛКСМ Өлкә Комитеты секретаре.

Кытайдагы сугыш хәрәкәтләрен күзәтү

Үткән атнада Көньяк Кытайда зур операцияләр булмады. Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә, Наньнин районында аерым сугышлар гына булды. Наньниннан көньяктарак японнар тылында хәрәкәт итүче кытай частьләре элемтә линияләрен бозалар. Японнар армиясенең шактый өлеше Наньниннан көньякка чигенде. Калган частьләр шәһәрне көчкә-көчкә генә кулларында тоталар. 27 нче февральдә япон гаскәрләре Патан районында кытайларны чолгап алырга маташтылар, ләкин барып чыкмады. Кытай частьләре оста маневрлар ясап японнарны шактый югалтуларга дучар итәләр. 24, 25 һәм 26 нчы февральдә Цзитан районында булган сугышларда японнарның 1.500 ләп кешеләре үтерелде һәм яраланды. Болардан тыш кытайлар ике орудие һәм 8 танк кулга төшерделәр. 26 нчы февральдә төнлә япон гаскәрләре көньякка таба чигенә башладылар.

Үзәк Кытайда февраль ахрында японнар командованиесе Нанкиннан көньяктагы районны кытай партизаннарыннан тазарту теләге белән Аньхуэй провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешенә таба бераз һөҗүм башларга маташты. Ләкин кытай гаскәрләре японнарга көтмәгәндә һөҗүм ясап, аларны зур югалтуларга дучар иттеләр. Нәтиҗәдә японнар чигенергә мәҗбүр булдылар.

Хэнань провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә Синьян тирәсендә сугышлар дәвам итә. Кытай гаскәрләренең һәм японнар тылындагы партизаннар отрядларының актив хәрәкәтләре япон гаскәрләренең операцияләренә комачаулык тудыра.

Төньяк Кытайда Уюань—Баотоу районында сугышлар бара. Бу сугышларда әле бер як, әле икенче як уңышка ирешә.

2 март. (ТАСС).

КЫТАЙ ГАЗЕТАЛАРЫ ВАН ЦЗИН-ВЕЙНЫ ФАШ ИТҮНЕ ДӘВАМ ИТТЕРӘЛӘР

ЧУНЦИН, 1 март. (ТАСС). Кытай газеталары 29 нчы февральдә Ван Цзин-вей интригаларын тагын да фаш итүгә багышлап, мәкаләләр басып чыгардылар. „Дагунбао“ газетасы Ван Цзин-вей бөтен Кытайны Япониягә сатарга тели, дип яза. Газетаның язуына караганда, документлардан японнарның Кытайдан Англия һәм Америка интересларын тулысынча куарга исәп итүләре күренә. „Шишисиньбао“ Кытайның барлык дусларын Япониягә каршы көрәштә Кытайга ярдәм итәргә чакыра.

„Саотанбао“ газетасы „хиянәтчеләргә каршы һәрбер кытай актив көрәшергә тиеш“ дип яза. Газета, әгәр без японнарның коллары булырга теләмәсәк, кораллы каршылык күрсәтүебезне көчәйтергә тиешбез, дип яза.

ТАТАР СОВЕТ КОМПОЗИТОРЛАРЫ

САЛИХ СӘЙДӘШЕВ

Бу хәл—моннан берничә ел элек булды.

Язның куәтле сулышы кешеләрнең йөзләренә бәрелә һәм яз урманнарга яшел көлмәк кидереп йөри иде ул чагында. Менә шул чагында лагерь урманнарын шаулатып, агач башындагы кошларны гаҗәпкә калдырып, җырлый-җырлый полк узды. Бу әле лагерьда беренче көннәр генә иде, шуңа күрә җыр да, урман да, майның дымлы төне дә—барсы да, барсы да аерууча әйбәт булып тоела иде. Без—дивизия штабы каршында чыга торган „Сугышчан постта“ газетасының сотрудниклары—алгы линейкаларга чыгып, полкның узганын карап калдык. Кызыл армеецләрнең җырларыннан һәм адымнарыннан көчле ритм, күтәренкелек, ашкыну һәм жанны рәхәтләндерә торган батыр моң бәрелеп тора иде. Без ирексездән берберебезгә караштык һәм полк турында, аның нинди көйне җырлавы турында үзара сөйләшә башладык.

— Сәйдәшев маршы, ул аны икенче полкның үз исменә атап язган,—диделәр безгә. Без Сәйдәшев исмен аңа чаклы да күп кенә ишеткәләгән идек инде. Язгы урман эчендә, хуш исле яшь чәчәкләр арасында, кошлар музыкасы һәм полкның күңелле җыры астында бу исем үзенә бер төрле тылсымлы янгырау белән янгырады...

Әнә шул рәвешчә Кызыл Армия частьләре өчен аерым маршлар язып, театрлар һәм полклар аша, мәктәпләр һәм консерватория аша ул — композитор Салих Сәйдәшев—24 елдан бирле инде халыкка хезмәт итеп килә. Аның көйләре эшче бистәләрдә дә, авыл клубларында да, кыр станнарында да, Академия театры сәхнәсендә дә—бар җирдә дә җырлана, аның көйләрен яратып җырлыйлар, яратып тыңлыйлар. Чөнки Сәйдәшев халык йөрәгенә якын булган моңнарны бик оста тотып ала һәм аларны үзенең иҗад казанында пешереп чыгара белә.

Күп кенә еллардан бирле музыка өлкәсендә эшләп, музыка аша халыкка хезмәт итеп килә торган Салих Сәйдәшев иптәшнең тормыш һәм иҗад юлы шактый кызыклы, ул, музыканы ишек төбенә дә җибәрми торган мещан катлавыннан чыгып, бер туктаусыз өскә—кояшка таба күтәрелүче кеше һәм ул үзенең бу матур күтәрелеш юлын, һич шиксез, бары тик Бөек Октябрь Социалистик революциясе яктылыгында гына таба алды. Әнә шуңа күрә без аны, безнең талантлы композиторыбыз Салих иптәш Сәйдәшевне Октябрь революциясенең безгә биргән җимешләреннән берсе итеп карыйбыз. Бүген—Татарстан Совет Республикасының XX еллыгын каршы алырга хәзерләнгәндә, бүген—формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культураның чәчәк атуын тагын бер кат билгеләп үткәндә Сәйдәшев турында шатланып сөйләмичә калып булмый. Чөнки Сәйдәшев фигурасы татар совет сәнгатендә кечкенә урын тотмый.

Салих Сәйдәшевнең әтисе Җәмалетдин Сәйдәшев элек Казанда Алат Шаһи дигән купецта кучер булып эшли, соңыннан кибет белән сату итә башлый. Җәмалетдин яшәп-яшәп тә дөньяны шак катыра алмагач, дөньяга ачулана да, улының тууын да көтмичә, аны әнкәсе корсагында калдырып, үлә дә китә. Бу—1900 нче ел була һәм бу 1900 нче елны, дөньяга үпкәләгән „аслы-өсле“ Җәмалетдин үлеп ике атна узганнан соң, аяк урнына тояк, дигәнсыманрак итеп Салих туа. Ләкин чынлыкта исә Салих аяк урнына тояк булып калмый, дөньяга үпкәләп үлгән Җәмалетдиннең улы Салих композитор Салих Сәйдәшев булып китә.

Әтисе үлгәннән соң Салих олы апасы Әминә Сәйдәшева тәрбиясенә күчә. Салих Казан мәдрәсәләрендә укып, аз-маз „этләнеп“ чыкканнан соң, Хәмитовлар кибетенә малай булып керә. Йомышка - юлга йөри башлый, чәйник белән чәй ташый, кагыла-сугыла, дөньяның иләк ягын да, күн ягын да күрә башлый, тик шулай да ул дөньяга буй бирмичә, музыка турында уйларга батырчылык итә. Малайлыкта йөргән чакта ук ул кичләренкичләрен буш вакыт табып музыка түгәрәкләренә йөри, төрле оркестрларда катнашып уйный башлый. 1916 нчы елны барсын да, шул җөмләдән, кибетче әфәнделәренең „шәфкатле һәм ышанычлы карашларын да“ артка ташлап, Гуммерт исмендәге музыкаль училищегә укырга керә. Училищенең карт укытучылары аның бармаклары клавишлар өстендә җиңел йөргәнлекне күрәләр һәм алар яшь үсмер Салихка карап:

— Син чынлап та музыка кешесе булырсың,—диләр.

— Ярый, мин риза,—ди Салих һәм ул әнә шул көннән башлап музыканың хрусталь сараенда хезмәт итәргә тотына.

Бөек Октябрь Социалистик революциясе яшь композиторга яңа иҗади канатлар бирә, ул „мин кем ягында калырга тиеш?“ дип аптырап, як-ягына каранып тормый, революциянең беренче көннәреннән башлап ук хезмәт ияләре ягында, большевиклар ягында калып җиң сызганып эшли башлый. Иң элек комклубта любительләрдән беренче кыллы оркестр оештырып, аңа җитәкчелек итә, аннан соң аны Буа шәһәренә хор-мейстер итеп чакыртып алдыралар. Әнә шул рәвешчә 1919 нчы елга чаклы Казан белән өяз калалары арасында йөргәннән соң, 19 яшьлек музыкантны өяз масштабындагы вакыйгалар генә канәгатьләндерми башлыйлар, ул нәрсәдер зурракны, көчлерәкне, бөтен йөрәк белән кичерә торганны эзләнә һәм 1919 нчы елны доброволец булып Кызыл Армия сафына китә. Музыкантның җилкәсенә шинель менеп утыра, музыкантның башына кигән шлемында кызыл йолдыз ялтырый башлый...

Салих Сәйдәшев Кызыл Армия сафларында 1921 нче елга чаклы калып, күп кенә урыннарда эшли һәм үзе дә күп кенә нәрсәләргә өйрәнә. 1921 нче елны ул Кызыл Армия сафыннан кайта, ләкин Кызыл Армиягә, кызыл йолдызга булган мәхәббәте анда һаман да шулай кайнар, һаман да шулай ялкынлы булып кала. Кызыл Армиягә һәм Кызыл Армия темасына ул әледәнәле әйләнеп кайта һәм һәр кайтуы саен үзенә бер төрле яңалык алып кайта. I нче һәм II нче полкларга багышланган хәрби маршлары Сәйдәшев иҗадының иң якты сәхифәләреннән берсе булып торалар. Кызыл Армия частьләре композиторның бу хезмәтләренә җавап итеп аңа берничә тапкыр рәхмәтләр белдерәләр, аны почетлы кызыл армеец итеп алалар һәм оборона наркомы иптәш Ворошилов композитор Салих Сәйдәшевне исемле сәгать белән бүләкли.

Кайчандыр, моннан күп еллар элек, Габдулла Кариевнең күчмә труппасында йөреп үзенең музыкантлык карьерасын башлаган 15 яшьлек музыкант, үзенең театры һәм традициясе булмаган музыкант, бүген безнең республикабызның атказанган сәнгат эшлеклесенә әйләнде һәм бүген аның үзенең театры, Академия театры дигән театры, үзенең исме, талантлы татар совет композиторы, дигән исме бар. Менә ул үзенең туган театрында, үзенең кабинетында, идәненә йомшак палас җәелгән һәм берничә гади рәсем белән бизәкләнгән кабинетында, сөйгән пианиносы каршында утыра һәм яңа язып бетереп килә торган „Наемщик“ операсыннан Гәрәй ариясен уйный. Аның матур бармаклары пианино клавишлары өстендә вак балыклар төсле булып сикерешәләр, чәче тузгып маңлаена төшә, күзләре очкынланалар, тәрәзәдән март кояшының шаян нурлары коелалар һәм талантлы композитор безне үзенең хиал өермәсенә ияртеп әллә кая—чыклы һәм сандугачлы таң алдына алып китә...

Без чын күңелдән рәхмәт әйтеп аңа баш иябез, без аның матур бармакларына саулык телибез, без аның кайнар йөрәгенә, гүзәллекне һәм халыкның чын моңын сизә белә торган нечкә йөрәгенә озын гомер телибез.

Фатыйх Хөсни.

КОНЦЕРТ-ЛЕКЦИЯЛӘР

Татарстан Дәүләт Филармониясе халыкны русның күренекле композиторлары белән таныштыру һәм гомумән рус музыкасының үсешен күрсәтү теләге белән 6 нчы марттан башлап концерт-лекцияләр үткәрә башлый.

Беренче концерт „Рус музыкасының чыганагы һәм Глинка“ дигән темада үткәрелә. Концерт барышында ТАССР Верховный Советы исемендәге Музыка училищесенең педагогы иптәш Френкин Глинканың тормышы һәм иҗады турында лекция сөйләячәк. Концерт-лекциядә Татар Дәүләт Опера театрының һәм Татарстан Дәүләт Филармониясенең артистлары катнашалар.

Март ахырларында „Даргомыжский һәм А. Рубинштейн“ дигән темада концерт-лекция үткәреләчәк.

ДРАМТҮГӘРӘКНЕҢ 5 ЕЛЛЫГЫ

Чистайдагы Культура йорты янында эшли торган татар драма түгәрәге үзенең оештырылуына 5 ел тулу көнен искә алырга хәзерләнә.

Бу түгәрәкнең әлекке членнарыннан Терегулова һәм Ибәтуллин иптәшләр хәзер Минзәләдәге совхоз-колхоз театры артистлары булып җитештеләр. Чукрак-телсезләр мәктәбе укытучыларыннан Салихова, Гатина иптәшләр, йорт хозяйкасы иптәш Габидуллина, пекарь Шәкүров һ. б. иптәшләр түгәрәктә зур сәләтлелек күрсәтеп, актив рәвештә эшләп киләләр. Түгәрәк членнары ике ел эчендә 32 спектакль куйдылар. Спектакльләр уңышлы үтәләр. Түгәрәк „Бишбүләк“, „Ташкыннар“, „Мактаулы заман“, „Козгыннар оясында“ һ. б. пьесаларны куйды. Ике ел эчендә түгәрәк 20 радиоконцерт бирде, клубларда 15 чыгыш ясады һәм 7 тапкыр колхозларда булды.

Түгәрәк членнары хәзер „Күзләр“ пьесасы өстендә эшлиләр һәм „Чаткылар“ пьесасын хәзерлиләр. Түгәрәк тарафыннан моннан 5 ел элек куелган бу пьеса, түгәрәк төзелүгә 5 ел тулу көнендә — апрель аенда яңадан сәхнәгә куелачак.

Татарстан АССР ның XX еллыгы көненә түгәрәк Мдиванинның „Намус“ дигән пьесасын хәзерли. (ТатТАСС).

1 нче мартта Казанда шәһәр беренчелеге өчен чаңгычылар ярышы башланды. РӘСЕМДӘ: „Медик“ спорт җәмгыятенең ярышка катнашучы физкультурник хатын-кызлары. М. Солтанов фотосы.

8 - МАРТ КӨНЕ АЛДЫННАН

ХАТЫН-КЫЗЛАР ҖИТӘКЧЕ ЭШЛӘРДӘ

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулардан соң Юдино районында уннарча хатын-кызлар җитәкче эшләргә күтәрелделәр.

Элекке батрачка, хәзер Шигали авыл советы башкарма комитетының председателе Агриппина Демидова колхозчылар массасы арасында зур авторитет белән файдалана. Ул—райсовет депутаты.

Райсовет депутаты, „Авангард“ колхозы хисапчысы иптәш Герасимова хәзер Әйшә авыл советының секретаре булып эшли. Күптән түгел ул ВКП(б) сафларына керде. Комсомолкалардан Башаева, Хисаметдинова һәм Чванина иптәшләр зоотехник булып, комсомолка иптәш Губанова раймелиоратор булып эшли.

Социализм эшенә чын күңелдән бирелгәнлекләрен күрсәткән алдынгы хатын-кызлар большевиклар партиясе сафларына керәләр. 1939 нчы елда партиягә кабул ителүчеләрнең 15 проценты хатын-кызлар. Алар арасында Зур Ключи авылының балалар бакчасы мөдире А. Петрова, Никольский мәктәбе укытучысы Матвеева, „Оборона страны“ колхозы хисапчысы Кириллова иптәшләр бар. Бу иптәшләр ВКП(б) членлыгына кандидат итеп, ә район сәламәтлек саклау бүлеге мөдире иптәш Касьянова, Васильево мәктәбе укытучысы Токинова һ. б. иптәшләр ВКП(б) члены итеп алындылар.

„ПРОМКООПЕРАТОР“ АРТЕЛЕНДӘ

Казан шәһәренең „Промкооператор“ артелендә 8 нче Март көненә кызу хәзерлек бара.

Алдынгы бригадалар һәм аерым стахановчылар производство планнарын системалы рәвештә арттырып үтәп киләләр. С. Сафина, Влогзарина, Гыйззәтуллина иптәшләрнең бригадалары планны 200 процентка якын арттырып үтиләр. Алдынгы стахановчы иптәш М. Васильева көнлек норманы 250—300 процент итеп үти.

8 нче Март көне уңае белән хатын-кызлардан 20 кеше „ГСО“ значогына норма тапшыруга хәзерләнә. 6 нчы мартта артель членнарының чаңгы походы оештырыла. 8 нче Мартта артельдә тантаналы җыелыш үткәрелә. Халыкара Коммунистик Хатын-Кызлар Көне—8 нче Март турында докладтан соң үзешчәнлек сәнгате көчләре тарафыннан концерт биреләчәк. Алдынгы стахановчылар бүләкләнәчәкләр.

8 нче Мартка актив рәвештә хәзерләнәләр

Казан Медицина институтының хатын-кыз яшьләре 8 нче Мартка актив рәвештә хәзерләнәләр. Бу көнне хатын-кызлардан 12 кешелек мотоциклчылар отрядына чыгарыш ясалачак, 20 кешедән радистлар түгәрәге оештырыла.

Институтта парашют эше зур популярлек белән файдалана. 8 студентка, шул исәптән Нина Заболотских, Соколова һәм Осипова иптәшләр самолеттан парашют белән сикерделәр.

8 нче Март уңае белән институтта хатын-кызларның атыш ярышы оештырыла. Һәрберсе 6 кыздан торган 2 команда ярышачак. Институтның фәнни работниклары арасында 11 комсомолка исәпләнә. Алар арасында оператив хирургия кафедрасы ассистенты—төз атучы иптәш Попова да бар. (ТатТАСС).

авыл Хуҗалыгы институты хатын-кызлары һәм техник работниклары ПВХО значогына нормалар тапшыралар. РӘСЕМДӘ: инструктор иптәш Б. Маринин институт работникларыннан О. Анисимова һәм М. Вәлиева иптәшләрне аэробомбаның төзелеше белән таныштыра.

Л. Попов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ЯҢА АПТЕКАЛАР

Хезмәт ияләрен дәвалауны яхшырту өчен шәһәрләрдә һәм авылларда аптекаларның челтәре елдан-ел киңәя бара.

Хәзерге көндә Казанда һәм районнарда Татарстан Аптекалар Идарәсенең 122 аптекасы, поликлиникаларда һәм амбулаторияләрдә 130 урында аптека пунктлары эшли. Быел районнарда 4 яңа аптека һәм 50 урында аптека пунктлары ачыла. Аптекаларда эшләү өчен быел янадан 50 провизор ярдәмчесе хәзерләнә.

Узган ел Татарстан аптекалары 25 миллион сумлык дару сатканнар иде. Быелгы план буенча аларның обороты 25 миллион 590 мең сум булырга тиеш.

ТАТАР МӘКТӘПЛӘРЕ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕКЛӘР

Татгосиздат быел башлангыч мәктәпләр өчен татар телендә 2 миллионга якын, 5—7 нче класслар өчен 1.665 мең данә һәм 8—10 нчы класслар өчен 247 мең данә дәреслек басып чыгарачак.

Мәктәп сериясендә С. М. Кировның, В. В. Куйбышевның, Салтыков-Щедринның, татар шагыйрьләреннән һәм язучыларыннан Һ. Такташның, Галиәсгар Камалның биографияләре, СССР халыкларының әкиятләре, Пушкинның „Капитан кызы“ һ. б. басып чыгарылачак. (ТатТАСС).

ТАТАРСТАНДА

Казандагы житен комбинатында 100 абонентлык телефон коммутаторы куелды. Хәзер барлык төп цехларда һәм бүлекләрдә телефон элемтәсе бар.

Элемтә работниклары союзының Татарстан Өлкә Комитеты местком председательләре һәм профсоюз активистлары өчен ай ярымлык курслар оештырды. Бу курсларда ВКП(б) ның XVIII нче съезды, ВЦСПС ның VI—VII—VIII нче пленумнары материаллары, география һәм СССР халыклары тарихы өйрәнеләчәк.

Союзкинохрониканың Казан студиясе 1939 нчы елны 37 кино-журнал һәм 1 кино-очерк чыгарды. Негатив кинопленкага 4 процент, позитив кинопленкага 11,1 процент экономия ясалды. Студия тарафыннан Татарстан кино-журналы өчен 155 сюжет, Бөтенсоюз кино-журналы өчен 10 сюжет эшләнде. Кино-журнал редколлегиясе бу сюжетларның 34 процентын яхшы һәм 49 процентын канәгатьләнерлек дип тапты.

Татарстанның Тәкәнеш районы Нырты совхозында тавышлы кино оештырылды. Шул уңай белән клуб 500 кеше сыярлык итеп яңадан җиһазландырылды.

ИНКУБАЦИЯ СТАНЦИЯЛӘРЕ ӨЧЕН ҖИРЛЕ ЯГУЛЫКТАН ФАЙДАЛАНУ

Татарстан инкубация-кошчылык станцияләренең күбесендә инкубаторлар ерактан китерелгән ташкүмер белән җылытылалар.

Тәрлекчелек буенча Татарстан өлкә тәҗрибә станциясенең фәнни сотруднигы иптәш Сабиров 1939 нчы елда инкубаторларны торф һәм соры ташкүмер белән җылыту тәҗрибәләрен үткәрде.

Арчадагы инкубация-кошчылык станциясендә „Спартак“ системасындагы инкубатор торф белән җылытылды. Моның өчен Казан якынындагы „Лебяжье“ күле янында чыгарылган торф китерелгән иде.

Әгерҗедә „Птицеводсоюз“ инкубаторын Иж-Бубы авылы янында чыгарылган торф белән җылыту тәҗрибәсе үткәрелде.

Чаллыдагы инкубация-кошчылык станциясендә инкубаторны Иске Тәкермән авылы янындагы соры ташкүмер белән җылыту тәҗрибәсе үткәрелде.

Тәҗрибәләр инкубаторларны җылыту өчен ерактан китерелә торган ташкүмер урнына торфны һәм соры ташкүмерне уңышлы рәвештә файдаланырга мөмкинлекне күрсәттеләр. Торф та, шулай ук соры ташкүмер дә йомыркаларны инкубацияләү өчен кирәк булган температура режимын бирә алалар. (ТатТАСС).

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

Хулиган. Ижевскийдан Казанга килгән Я. Н. Карасев дигән кеше Чернышевский урамында төрле кешеләргә бәйләнеп йөргән, почта конторасына кереп зур тавыш куптарган. Соңыннан ул почта конторасының ике зур тәрәзә пыяласын ватып 7.000 сум зарар китергән. Карасев тотылып җавапка тартылган. Тәрәзә пыялалары ватылудан килгән зарарны аннан түләтергә чаралар күрелә.

БЕЛДЕРҮ

4 нче март, кич 7 сәгатьтә Казан Дәүләт университетының актовый залында Казан шәһәре Молотов районы өчен лекция була. Тема: „Социализм һәм көнкүреш“. Лектор—иптәш Устюжанин.

Җаваплы редактор урынбасары И. УЗБЕКОВ.

Зам. ответ. редактора И. УЗБЕКОВ.

Өметле талант

(МӨНИРӘ БУЛАТОВА КОНЦЕРТЫ)

Моннан берничә еллар гына элек Казандагы киез итек фабрикасында лаборантка, аннан соң кичке музыка техникумында, ә аннан соң Москва консерваториясе янындагы студиядә уку—талантлы яшь җырчы Мөнирә Булатованың үсү юлы менә шушындый.

„Качкын“, „Ирек“ опералары һәм радио аша булган чыгышлары белән без аны белә идек инде. 2 нче мартта язучылар союзы тарафыннан оештырылган иҗад концертын тыңлап, без җырчы Мөнирә Булатова белән тагын да якыннанрак таныштык.

„Гөрләсен безнең җыр“, „Партизаннар“ кебек җырларны зур осталык белән, җиддилек белән бирелеп җырлады, ә, „Гөлнәзирә“, „Җиләк җыйганда“ кебек җиңел көйләрне ачык елмаю белән оста башкара алуы Булатованың универсаль җырчы булып өлгереп килүен тагын бер кат раслыйлар.

Тирән моң белән тулган „Соңгы очрашу“, „Сагыну“, „Соңгы мәртәбә“ шикелле көйләр дә аның тарафыннан гаять зур осталык белән башкарылды.

Булатова болардан башка тагын берничә авыл көен дә башкарды. „Авыл көе“ (татар халык көе), „Бишбүләк“тән „Өмә җыры“н тыңлаучыларның кабат-кабат сорап җырлатулары солистканың осталыгын, халык көйләрен җиңел җырлавын күрсәтәләр.

„Өмә җыры“ „Бишбүләк“тә хор белән бара. Ә, Булатова тарафыннан бирелгән бу көй һичбер төрле кимчелексез залга бөтен тулылыгы белән барып җитте. Тыңлаучылар бу көйне дә зур күтәренкелек, озак кул чабулар белән кат-кат җырлаттылар. Бу, чыннан да өмә җыры, күңел ачу җыры булды.

Кыска гына концертта яшь талантның универсальлыгы нык кына ачылып җитте. Язучылар, журналистлар җәмәгатьчелеге Булатованың җырларын яратып тыңладылар.

Гариф Миңнул.

Бензин һәм майлау материаллары станциясе конторасы

БАРЛЫК АВТОХУҖАЛЫКЛАР ИГТИБАРЫНА

БЕЛДЕРӘ:

Татарстан АССР Совнаркомының 1940 нчы ел, 26 нчы февральдә чыгарган 103 нче номерлы карары нигезендә,

автохуҗалыкларны ягулык һәм майлау материаллары белән тәэмин итү һәм аның учеты буенча яңа тәртип кертелә

Шул уңай белән, автохуҗалыклар кулларында булган барлык талоннарны шәһәрдә 10 нчы мартка кадәр, районнарда 15 нче мартка кадәр, ягулык һәм майлау материаллары станциясенә тапшырырга һәм яңа талоннар алу чарасын күрергә тиешләр. Элекке талоннар шушы ел 1 нче марттан гамәлдән чыккан дип исәпләнә.

Талоннар тапшыручы оешмалар, тапшырылган талоннарга счет язарга тиешләр һәм счетта ул тапшырылган талоннарның бензин һәм майлау материаллары станциясе кассасыннан нинди номерлы счет буенча алынган булуы күрсәтелергә тиеш. 396—3—1

13 нче март, кич 6 сәгатьтә В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан Дәүләт университетының зоология аудиториясендә (43 нче бүлмә) университет биология факультеты гыйльми советының ачык утырышы чакырыла һәм биология фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен иптәш Л. И. Соснин тарафыннан халык алдында

ДИССЕРТАЦИЯ

яклау үткәрелә

Тема: „Кавказ заповеднигы урманнары“.

Рәсми оппонентлар: доцент М. В. Марков һәм доцент Л. Н. Васильев.

Утырышка Казан ВУЗ ларының фәнни работниклары чакырылалар. 421—1

КАМИЛЬ ЯКУБ ИСМЕНДӘГЕ

КИТАП ФАБРИКАСЫ

хәреф җыючылар һәм хәреф таратучылар хәзерләү курсларына шушы ел, 15 нче мартка кадәр

УКУЧЫЛАР АЛА

Курсларга 18 яшькә җиткән кешеләр алыналар. Курсантларга стипендия бирелә. Тору урны бирелми. Квартира акчасы бирелә. 417—1

Юдино районы „Пахарь“ колхозының югалган 6 кырлы каучук печатен гамәлдән чыккан дип санарга. 327—1

Горпромторгның 11 нче магазины хәзер акчасыз расчет буенча предприятиеләргә, учреждениеләр һәм оешмаларга, тимер-калай, москатель-химик товарлар һәм һәр төрле төзү материаллары сата.

Магазинның адресы: Бауман урамы, 9/11. 385—2—1

Казан Финанс-Экономик институт төзелеше конторасы 3 тонналы

ИКЕ АВТОМАШИНА

һәм йөк ташу өчен, барлык җигү әйберләре белән,

5—6 БАШ АТ САТЫП АЛА

Тәкъдимнәр өчен адрес: Казан, Бутлеров урамы, 4, КФЭИ төзелеше. 400—1

РЕММАШТРЕСТ

Чернышевский урамындагы 2 нче йорттан Тукай урамындагы 5 нче йортка (ишек алдында)

КҮЧТЕ

401—1

Машиналар төзү заводы

җиңел һәм йөк автомобильләре

сатып ала

41—54 һәм 16—22 телефоннары буенча яисә почта адресы буенча М. Ф. Шиховка мөраҗәгать итәргә. 36 нчы почта бүлеге, почта ящиге 732. 373—5—3

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ

Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры бинасында

4 нче һәм 9 нчы мартта

ИРЕК

Талоннар: бүген 82, 9 нчы мартта 84.

Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.

Зур Драма театры бинасында 7 нче мартта

ЗУР КОНЦЕРТ

Талон 83. Кич 9 да башлана.

Билетлар Зур театр кассасында сатыла.

Коллектив рәвештә килү өчен 28—04 телефоны буенча заявкалар алына.

Киров районындагы

КУЛЬТУРА САРАЕНДА

Татар Дәүләт Опера театры постановкалары

5 һәм 6 нчы мартта

Файдасызга саклану

Талоннар: 5 нче мартта 62, 63 һәм 6 нчы мартта 64, 65.

Кич 8 дә башлана.

КИРӘК:

Даими эшкә НАБОРЩИКЛАР һәм КӘГАЗЬ КИСҮЧЕЛӘР. Казан, Пионер урамы, 27. 399—1

11 нче трестның Транспорт конторасына БУХГАЛТЕР-ФИНАНСИСТ ҺӘМ АЕРЫМ БАЛАНС БУЕНЧА ЭШЛӘҮ ӨЧЕН ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР. Хезмәт хакы килешү буенча. 319—3—3

Татнаркомхозның Мелиорация-Гидротехника конторасына ИНЖЕНЕРЛАРДАН: ГИДРОТЕХНИКЛАР, ТӨЗҮЧЕЛӘР, ГИДРОГЕОЛОГЛАР. ТЕХНИКЛАРДАН: ТӨЗҮЧЕЛӘР, ГИДРОТЕХНИК-ИНВЕНТАРИЗАТОРЛАР, САНТЕХНИКЛАР, КОЛЛЕКТОРЛАР, БОРАУЛАУ МАСТЕРЛАРЫ. Шунда ук ЯРДӘМЧЕ ЭШЧЕЛӘР. Казан, Кремль, 3 нче подъезд. 330—5—3

Индивидуаль заказлар буенча аяк киемнәре тегү мастерскоена даими эшкә КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ ИТЕКЧЕЛӘР һәм БАШМАКЧЫЛАР. Университет урамы, 2/51 Телефон 11—48. 359—5—4

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

5 нче мартта

ШӘМСЕКАМӘР

(талон 127).

Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

4 һәм 5 нче мартта

ЛЕНИН

Талоннар: бүген 115, иртәгә 116.

Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына. Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген, 4 нче мартта, данлыклы

ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ

300 хайван һәм кошлар катнаша һәм башка күп номерлар.

РСФСР ның атказанган артисты һәм орденлы **М. ЗОЛЛО**ның

соңгы гастрольләренә билетлар сатыла.

Уен кич 8 дә башлана.

Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ЯШӘРГӘ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДУСЛАР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8 һәм 10 да	ПАТРИОТ
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ДОШМАН ИШЕК ТӨБЕНДӘ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	БЕТХОВЕН КОНЦЕРТЫ. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	УКЫТУЧЫ
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
КУЛЬТУРА САРАЕ 4-30, 7, 9 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 736 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА. ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 880.